• ӘҢГӘМӘ •
ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН: «ТАТАР ТЕЛЕ ХАКЫНДА ШИГЕМ БУЛМАДЫ»
*4-5 бит*

• РАМАЗАН •
УРАЗАНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ
*7 бит*

• САБЫЙГА•
КОРЪӘННЕ МАТУР ИТЕП УКУ
*9 бит*

• НӘСЫЙХӘТ •
ИГЕЛЕК КЫЛУНЫҢ ЛӘЗЗӘТЕ
*12 бит*

*№ 3 (308)* *Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы* *шәгъбан-Рамазан 1442*

*март, 2021*

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ




*Рамазан аенда ураза тоту Ислам диненең өченче нигезе булып тора. Ураза тоту Һиҗрәтнең икенче елыннан башлап фарыз булган. Ураза тоту – таң атканнан алып кояш баеганчыга тикле ашау-эчүдән һәм җенси якынлыктан тыелып торуны аңлата.*

*Дәвамы 7 нче биттә*

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# Татарстан мөфтие һәм КФУ ректоры хезмәттәшлек турында меморандумны имзалады

***19 нчы мартта Казанда ТР мөселманнары Диния нәзарәте һәм КФУ арасында хезмәттәшлек турында меморандумны имзалау тантанасы узды. Документны Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры Илшат Гафуров имзалады.***




Очрашуда шулай ук ТР мөфтиенең урынбасары, РИИ һәм КИУ ректоры Р. Мөхәммәтшин, ТР мөфтиенең мәгълүмати сәясәт буенча киңәшчесе, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты генераль директоры Р. Хәмидуллин, КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры Р. Хәйретдинов, университет һәм мөфтият арасындагы хезмәттәшлек юнәлешләре буенча җитәкчеләр катнашты.

КФУ һәм ТР МДН арасында мондый тарихи документ беренче тапкыр имзаланды. Меморандум аерым юнәлешләр буенча уртак проектларны гамәлгә ашыруда хезмәттәшлекне күздә тота. Әлеге меморандум кысаларында массмедиа өлкәсендәге уртак проектларны, фән һәм мәгърифәтчелек эшчәнлеге белән бәйле уртак проектларны һәм чараларны гамәлгә ашыру, шулай ук мәгърифәтчелек һәм белем бирүнең сыйфатын яхшыртуга ярдәм итү; чараларны мәгълүмати һәм оештыру ягыннан тәэмин итү, аларны әзерләүгә һәм үткәрүгә ярдәм итү; бергәләп заманча белем бирү системаларын төзү һәм куллану; булачак чаралар турында мәгълүмат алмашу; экстремизмга һәм террорчылыкка каршы тору кысаларында уртак проектларны гамәлгә ашыру; ике як уздыра торган иҗтимагый чараларга мәгълүмати ярдәм күрсәтү; татар дини мирасын саклау һәм популярлаштыру өлкәсендә уртак проектларны гамәлгә ашыру һәм башка юнәлешләрдә уртак гамәлләр кылырга килешенде.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты генераль директоры Р. Хәмидуллин хәбәр иткәнчә, мөфтият һәм КФУ бу вакыйгага күптән әзер булган. «ТР мөселманнары Диния нәзарәте дә, Казан федераль университеты да уртак бер эш – мирасыбызны саклау белән шөгыльләнәбез. Очрашу һәм фикер алышулар нәтиҗәсендә без көчләребезне берләштерергә, бу юнәлештә эшне көчәйтергә һәм үзара хезмәттәшлек турында килешүгә кул куярга булдык. Без төрле юнәлешләрдә эшләячәкбез: бу китаплар белән эшләү дә, ТВ да, студентлар белән аралашу да», – диде Р. Хәмидуллин.

КФУ ректоры И. Гафуров фикеренчә, бу көн ике оешма өчен дә мөһим. «Әлеге килешүне имзалаганда, без мөнәсәбәтләребезне рәсмиләштерәбез. Безнең элек-электән килгән мирасыбыз бик зур. Бу мирас бүген яңа буыннар өчен өйрәнүгә, аңлауга һәм тапшыруга мохтаҗ. Бу эштә без үз тырышлыгыбызны, барыннан да элек, Татарстан Диния нәзарәте, бүгенге көндә Санкт-Петербургта урнашкан Көнчыгыш кульъязмалар институты белән җайга салабыз», – диде И. Гафуров. Килешүнең төп предметы дип ул борынгы хезмәтләрне цифрлаштыруны атады.

– Бу мәсьәләдә эшнең башында ТР мөселманнары Диния нәзарәте тора, чөнки нәкъ менә мөфтиятнең мөмкинлекләрен файдаланып, без үсеп килүче буынга һәм кызыксынучы затларга мирасны җиткерә алабыз. Бу Болгар ислам академиясенә дә, ТР мөселманнары Диния нәзарәте канаты астында эшли торган башка күпсанлы уку йортларына да кагыла. Уртак эшчәнлек нәтиҗәсендә зур мөмкинлекләр ачыла. Әлбәттә, бу эшне бераз иртәрәк эшләргә кирәк иде. Без бүген бу эшкә «өлгердек». Шуңа күрә бу башлангыч белән чыккан Камил хәзрәткә зур рәхмәт белдерәсе килә. Халыкара мөнәсәбәтләр институты, көнчыгышны өйрәнүче югары мәктәп җитәкчесенә, бу эш белән турыдантуры шөгыльләнүче барлык кешеләргә рәхмәт», – диде КФУ ректоры, бу килешүне имзалаганнан соң тагын да көчлерәк эшчәнлеккә өметләнеп.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең сәламләү сүзендә билгеләп үткәнчә, башкалабыз һәм республикабыз кунакларын, беренче чиратта, татарстанлыларга хас татулык һәм толерантлык традицияләре гаҗәпләндерә. «Алар моның сәбәбенә төшенергә тырыша. Һәм без бу уңайдан һәрвакыт төрле чагыштырулар, төрле фикерләр ишетәбез. Әмәшһүр тарихчы Михаил Худяков үзенең «Казан ханлыгы очерклары» дигән китабында безнең Казан ханлыгында православие гыйбадәтханәсе булганлыгын мисалга китерә. Без бу толерантлыкның чишмә башы татар мирасында булуын аңлыйбыз.

Алда әйткәнчә, Петербургта татар халкының рухи мирасына караган 12 мең хезмәт саклана. Ягъни безнең ата-бабаларыбыз өйрәнүне көтеп тора торган зур байлык, бик зур дәрьяга тиң хәзинә калдырган. Аллаһы боерса, без барысын да бергә эшләячәкбез. Чыннан да, моңарчы да эш алып барылды инде. Бүген, Илшат Рәфкать улы әйткәнчә, без бу мөнәсәбәтләрне рәсмиләштерәбез. Без иң яхшы университетларның берсе булган КФУ белән эшләвебезгә шат. Безнең бөек галимебез Мәрҗани шушы университетта укыткан. ИншәАллаһ, без яхшы уңышларга ирешәчәкбез. Иң мөһиме – без бу юлга кердек», – дип белдерде мөфти.

КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры Рамил Хәйретдинов сүзләренә караганда, бүгенге вакыйга гадәти түгел. «Монда сүз тамырдан үзгәреш – Казан федераль университетының, дөньяви белем бирә торган уку йорты буларак дини белем бирү системасы бәйләнышлары турында бара. Дини белем бирү системасы башында ТР мөфтиятен җитәкләгән Камил хәзрәт тора. Без алдагы берничә ел дәвамында, бигрәк тә Идел буе Болгарстаны тарафыннан Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан, тарихи-мәдәни мирасыбызны өйрәнүдә мөмкин кадәр алга китеш ясарга тиешбез дип саныйбыз», – диде Р. Хәйретдинов.

– Дөрес әйтәсез: мирасыбыз меңләгән, дистәләгән мең саклау берәмлеге белән санала, – дип дәвам итте ул сүзен. – Һәм шунда ук бу мирасның куркыныч астында булуы һәм бик начар шартларда саклануы турындагы бәхәсле сөйләшүләрне кире кагарга кирәк. Сезне КФУга, сирәк кульъязмалар бүлегенә чакырабыз һәм сез коллекциянең иң ышанычлы кулларда булуын күрерсез. Шулай ук коллекцияләр Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында һәм башка шәхси коллекцияләрдә саклана. Алардан Илшат Рәфкать улы, Камил хәзрәт карары белән киң җәмәгатьчелек файдалана алачак», – диде ул. Ришат Хәмидуллин җитәкләгән «Хозур» нәшриятына Darul-Kutub.com. проекты өчен аерым рәхмәт белдерде.

Рамил Хәйретдинов шулай ук Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең электрон китапханәсендә басылган язмаларның фәнни яктан шәрехләнәчәген һәм аларның Рәсәй укучылары өчен генә түгел, чит илләр өчен дә ачык булачагын ассызыклады. «Беренче этапта без әле татар, шул исәптән дини дәреслекләрнең тулы каталогын әзерләргә телибез. Үз вакытында алар XIX-XX гасырларда гомумтөрки, гомуммөселман киңлекләрендә иң яхшы дәреслекләр булган басмаларның саны дистәләрчә меңгә җиткән. Шуңа күрә якын арада без бу байлыкны бәяләп кенә калмыйча, аны заманча, шул исәптән, белем бирү процессында да актив куллана алырбыз дип өметләнәбез», – диде ул.

Татарстан мөфтиенең мәгариф буенча урынбасары, КИУ һәм РИИ ректоры Рәфикъ Мөхәммәтшин сүзләренчә, милли-дини бердәмлекне һәм ватанпәрвәрлекне саклау турында сөйләгәндә, үз мирасыңа карата битараф булырга ярамый. Аннан башка киләчәк турында тулы канлы күзаллауларны формалаштыру мөмкин дә түгел, дип билгеләп үтте ул. «Бу күзлектән караганда, бай мирасны өйрәнү буенча әлеге килешү бик өметле», – диде Р. Мөхәммәтшин.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

# Мөфти «Яшь килен» проектында катнашучылар белән очрашты

***18 нче мартта мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Диния нәзарәте гамәлгә куйган «Яшь килен» проектында катнашучы мөслимәләр белән очрашты.***

Очрашуда сүз Коръән кушканча яшәү, мөслимәнең сыйфатлары, дәгъват кылу нигезләре, Аллаһының ризалыгына ирешү юллары, гыйлем алуның әһәмияте, гаиләдә ир-атның һәм хатын-кызның бурычлары хакында барды. Сөйләшүнең темасы «Коръәндә — кыз, хатын, ана» дип билгеләнгән иде, шуңа да мөфти хәзрәт очрашуда катнашучыларга Коръәннән аятьләр китереп, хатын-кызның күркәм сыйфатларына тукталды. Ни өчен иң беренче өстен сыйфатлардан хатын-кызларда тыйнаклык, ә ир-атларда тәкъвалык булырга тиешлеген аңлатып узды.

Камил хәзрәт Коръәндә барлык сорауларга да җаваплар бар, дип белдерде һәм хатын-кыз нинди булырга тиеш дигән сорауга җавапны «Әл-Касас / Кыйсса» сүрәсеннән табып бирде. Әлеге сүрәдә Муса галәйһиссәламнең Мисырдан качарга мәҗбүр булуы хакында әйтелә. Ул ике төп юлга түгел, ә тар юлга кергәнлектән, аны куып җитә алмаганнар. Шулай итеп ул сигез төн буена яланаяк хәлдә булган һәм агач яфракларыннан башка берни дә ашамаган. Әмма Аллаһы Тәгаләгә карата тәвәккәллеген һәм яхшы уен һич бозмаганы өчен, Раббысы аңа Җәбраил галәйһиссәламне җибәргән һәм Мәдйәнгә юлны күрсәткән.



Алга таба Муса галәйһиссәламнең, пәйгамбәр кызларының берсен үзенә никахландыру өчен, Шугаеб галәйһиссәламдә ун ел хезмәт итүе хакында әйтелә.

– Пәйгамбәр кадәр пәйгамбәр әлеге кызның әтисенә ун ел хезмәт итү шартына ризалык бирә. Ә бу кыз хакында без ниләр беләбез соң? Аның нинди сыйфатлары бар? – дип мөрәҗәгать итте мөфти яшь мөслимәләргә. – Коръәндә аның буй-сыны турында әйтелгәнме? Юк. Ул бары яшь бер кыз. Аның иң беренче күркәм сыйфаты – ул тыйнаклык. Хатын-кыз, әни, әби өчен иң җитди сыйфат нәрсә? Ул – тыйнаклык. Аннары бу кыз турында ниләр беләбез? Ул акыллы. Әтисенә нәрсә дип әйтә? «Әйдә без аны эшкә алабыз, чөнки ул көчле, ышанычлы (тәкъва), ди. Без якынлашкач, ул безгә карамады, сорагач – ярдәм итте». Кызы әтисе Шугайб галәйһиссәламгә шундый киңәш бирә. Шуңа күрә балаларны игелекле итеп тәрбияләргә кирәк, алар киңәшчеләр булсыннар.

Аннары Камил хәзрәт чын ирләрнең сыйфатларын санап үтте: беренчесе – сәүдә эшләренең зикер кылудан тыймавы; икенчесе – биш вакыт намазны җәмәгать белән тиешле рәвештә үтәргә тырышу; өченчесе – зәкят түләү; дүртенчесе – Кыямәт көненнән, Кубарылу көненнән курку. Бу дүрт сыйфат ир кешеләрдә булырга тиеш. Әгәр шушы сыйфатлар булса, без үзебезне ир-кешеләр, батырлар дип атый алабыз, диде мөселманнар башлыгы.

Алга таба «Яшь килен» проектында катнашучылар никахның шартлары, танышу кагыйдәләре, хитб (ярәшү, димләү), ир белән хатынның вазифалары буенча үзләрен кызыксындырган сорауларны бирде.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

---

# «Мөхәммәдия»дә Туган телләр елы уңаеннан Коръән бәйгесе узды

***19 нчы мартта «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә I-V курс шәкертләре арасында Коръән уку бәйгесе үткәрелде.***

Әлеге чараны уку йорты мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның хәерфатыйхасы белән Татарстан мөфтияте белән бергәлектә оештырды. 1994 елдан бирле һәр уку елында мәдрәсә күләмендә үткәрелеп килә торган бәйге быел Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында узды һәм, башка еллардан аермалы буларак, шәкертләрнең аять-сүрәләрне татар мәкаме белән укуларына басым ясалу белән аерылып торды.



Мәдрәсә күләмендә үткәрелә торган бәйгедә көндезге уку бүлегендә белем алучы барлык шәкертләр – барлыгы 207 укучы катнашты. Төп шарт – Коръәнне дөрес итеп яттан уку белән беррәттән, уку елы дәвамында Изге Китапны ятлауда ирешкән уңышларыңны күрсәтү, аятьләрне кабатлау, белемне ныгыту өчен мөмкинлекләр тудыру. Шуңа да катнашучылар өчен номинацияләр җөзләрне белү дәрәҗәсенә карап билгеләнгән. Коръәнне күбрәк яттан белүчеләрнең призлы урыннарга чыгу мөмкинлеге дә ата. Бәйгедә Коръәнне ятлау (тәхфиз) бүлегендә белем алучы шәкертләр катнашмый.

Номинацияләргә килгәндә, «Тулы Коръәнне яттан белүчеләр», «Алты җөзне яттан белүчеләр», «Биш җөзне яттан белүчеләр», «Дүрт җөзне яттан белүчеләр», «Өч җөзне яттан белүчеләр», «Ике ярым җөзне яттан белүчеләр», «Ике җөзне яттан белүчеләр», «Бер җөзне яттан белүчеләр», «Ярты җөзне яттан белүчеләр» арасында урыннар билгеләнде. Бәйгедә егетләр һәм кызлар аерым көч сынашты.

Мәдрәсә күләмендә үткәрелгән Коръән бәйгесе республикакүләм һәм Рәсәйкүләм бәйгеләргә иң яхшы Коръән укучыларны сайлап алырга ярдәм итәчәк.

■ **dumrt.ru** сайтыннан

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН:**

# «Татар теле хакында бервакытта да шигем булмады»

*Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан, без татар теленең бүгенге хәле һәм аның киләчәге хакында сөйләшеп алырга булдык. Бүгенге әңгәмәдәшебез – күптән түгел генә 80 яшьлек юбилеен уздырган Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры, диктор Фоат Галимуллин*

## «Үзебезнең Эльс Гаделев»

**– Фоат абый, Сезнең хакта сүз чыгуга, беренче чиратта, укытучы, профессор түгел, «Татарстанның алтын тавышы» булып күзалланасыз. Дикторлык хезмәтегез нидән башланды?**

– Ул үзеннән-үзе, көтелмәгәндә булды. Әле армиягә кадәр Кукмарада театр коллективын җитәкләдем. Көннәрдән бер көнне мәдәният йортына өстәл кадәр магнитофон кайтардылар. Гадәти магнитофон юк вакыт, ә монда зур, профессиональ аппаратура. Коллектив шул магнитофонга җырлар, аудиоспектакльләр яздыра башлады. Берсендә Галимҗан Сәгыйдуллинның «Тамырлар» әсәре буенча куелган спектакль, уңышның нәрсәгә бәйле булуы, режиссёр буларак, нинди максатлар куелуы турында сөйләргә тәкъдим иттеләр. Сөйләдем. Соңыннан язманы тыңлаучылар: «Казанда «Татарстан» радиосында Эльс Гаделев дигән диктор бар. Синең тавыш тембрың аныкы кебек икән. Сиңа да диктор булырга кирәк», – диделәр. Җырлап йөреп танылу алып өлгергән идем инде. Ә менә сөйләм мәсьәләсендә тавышымның ниндидер сәнгатьчә әһәмияте турында берninди дә хәбәрем юк иде. Җырлаганда тенорга тартымрак җырлыйм, ә сөйләгәндә, үзеннән-үзе баритон тавыш белән сөйли башлыйм. Әле баритонның да түбәнрәк рәвеше. Менә шул магнитофон язмасы ярдәмендә аңладым да инде тавышымның аермасын һәм үзенчәлеген.

Соңрак Кукмара радиоузелы аша җирле тапшырулар оештыра башладылар. Мәдәният йортында эшләгән кеше булганга, тапшыруларның берсен алып барырга сорадылар. Беренче тапшыру чыккач та, «Үзебездә дә «Татарстан» радиосында кебек дикторларыбыз бар икән», – дип шалтырата, яза башладылар. Шул рәвешле, ике ел Кукмара радиоузелы аша атнага 1-2 тапкыр эфирга чыгып килдем.

## «Без бит сине ничә елдан бирле эзлибез!»

– 1967 елда армиядән кайткач, Рәсәй күләмендә Совет хакимиятенең 50 еллыгына багышланган фестиваль уздырылды. Кукмара вәкиле итеп Казанга җибәрделәр. Ә Казаннан 3 кешене Рәсәй фестивалено сайлап алдылар: сопрано тавышлы консерватория тәмамлаган профессиональ җырчы – Әлфия Борнашева, Минзәлә ягыннан Кәбир Нигъмәтҗанов һәм мин. Җырлау культурасын яхшырту өчен, Кукмарадагы эштән аерып, Казанга Консерваториягә вокал буенча дәресләргә чакыртып алдылар. Тавыш кую буенча укытучы, профессор Зөһрә Бәйрәшева кул астында 4 ай укыдым: тавыш куярга, җырлаганда тавышны, сулышны дөрес файдаланырга өйрәттеләр. Әлеге курсның файдасы бик зур булды. Куйбышев (хәзерге Самара – ред.) шәһәрендә узган Рәсәйкүләм фестивальдән югары дәрәҗәле диплом белән кайттым.

Фестивальдән соң 1-2 җырны яздырырга, фестиваль, хис-кичерешләр турында сөйләргә дип радиога чакырдылар. Студиягә кердем дә сөйли башладым. Фәүзия Бурнашева «Туктагыз!» дип мине туктатты да, студиядән чыгып йөгерде. Бераздан унбишләп кеше җыеп керде. Барысы да оператор янына утырып, тәрәзә аша гына безне күзәтә башлады. Фәүзия апа белән әңгәмә тәмамлангач, карап утыручыларның берсе – мәһабәт гәүдәле, күзлекле ир-ат, студиягә кереп мине кочаклап алды да: «Кайда йөрисең син? Без бит сине ничә елдан бирле эзлибез!» – диде. Менә шуннан профессиональ диктор итеп эшкә чакырдылар. 5 ай эчендә фатир да бирделәр, хәтта.

**– Телгә карата мәхәббәт дикторлык эше белән бәйлеме?**

– Ул мәхәббәт бар иде инде. Татар теле һәм әдәбиятына карата минем беркайчан да шигем булмады, чөнки татар мохитендә үстем. Ләкин татар теленең мөһимлеген, халык өчен ни дәрәҗәдә кирәк булуын дикторлык хезмәте башлангач кына аңладым. Ул вакытларда татар телендә сөйли торган радио иң көчлеләрдән булды. Төпле телевидение дә юк бит әле. Бары тик безне генә тыңлыйлар. Башкортстан, Пермь, Ульяновск, Киров өлкәләреннән хатлар килде радиога.



## Телләр ник үлә?

**– Фоат абый, телләрнең үлүенә кем сәбәпче?**

– Дөньяда 6000нән артык тел бар, дип әйтелә. Дөрес, соңгы вакытларда 5000 дип тә әйтә башладылар, ягъни кими бара. Әле соңгы көннәрдә генә мине бер вакыйга тетрәтте. Ерак Көнчыгышта – Камчатка ягында бер әби вафат булган. Әлеге әби милләте буенча алеут һәм шул телне белгән бердәнбер кеше булган. Телнең бетүе менә шулай да була икән! Без телнең бетүен күз алдына да китермибез. 5000 дигән вакытта, әле азмы-күпме яши торган телләр күз алдында тотыла торгандыр. Әлбәттә, аның зурлары да бар. Мәсәлән, кытай теле. Бу телдә миллиард ярым, ике миллиард кеше сөйләшә. Яки Һинд илендәге телләр, шулкадәр күп миллионлы кешеләр сөйләшә бит. Аннан өченче урында – инглиз теле. Ул дөньяны иңләп алды һәм төп телләрнең берсенә әйләнеп бара.

Телләрнең бетүенә нәрсәләр тәэсир итә соң? Әлбәттә, иң элек глобальләштерүне атап китәргә кирәк. Чөнки теге яки бу телдә сөйләшүче халыкның күплегенә бәйле, кайбер телләр ничектер өстенлек алырга тырышалар. Башка телләрне кысу хисабына үзләренең яшәү даирәләрен киңәйтергә омтылалар. Инглиз теле моңа ачык мисалдыр инде. Россиядә, мәсәлән, рус телен мисал итеп китерергә була.

Икенче сәбәп – урбанизация, шәһәрләшә бару. Авыллардан шәһәргә күчәләр һәм монда әнә шул шәһәрләрдәге глобальлек авыллардан килгән кешеләрне тел җәһәтеннән йота, төп телдә сөйләшүгә күчерә һәм бу туган телләргә бик зур зыян китерә. Безнең бурыч – шәһәр шартларында да туган телләрне саклау, үстерү өчен мөмкинлекләр табу.

Өченчесе беренче һәм икенчесеннән килеп чыга. Ул да булса – ассимиляция. Татар теленә, шөкер, бүгенге көндә әле андый юкка чыгу куркынычы янамый.

*«Безнең бурыч – шәһәр шартларында да туган телләрне саклау, үстерү өчен мөмкинлекләр табу»*

## Татар теленең үзенчәлеге нидә?

– Безнең халкыбыз күп миллионлы һәм аның холкының һәм яшәү рәвешенең бик әһәмиятле үзенчәлеге бар: кая гына барса да, кайда гына яшәсә дә, үз теленнән ваз кичмәү. Өй шартларында гына булса да, балаларга, яшь буыннарга телне өйрәтү һәм мөмкинлек булганда, мәктәпләр оештырып уку, укуны җайга салу.

Мәсәлән, патша Россиясендә дәүләт татар мәгарифен үстерүгә бер тиен дә бирмәгән. Ә татар халкы Рәсәй Федерациясендә иң укымышлы халык булып яшәгән, чөнки халык үзе, үз хисабына мәктәп-мәдрәсәләр булдырып, балаларын укыткан һәм язарга өйрәткән. Шуңа күрә әдәбиятыбыз да мең елдан артык үсеш кичергән. Кайсы халык шулай әйтә ала?!

Борын-борынгыдан дәүләтле халык булгач, киң даирәләрдә дәүләт төзеп яшәгән халык буларак, татар халкында укуга, телне үстерүгә, саклауга, әдәбиятыбызга булган мәхәббәт һәм омтылыш бервакытта да сүнмәгән. Менә шул безгә татар теленең дә дөнья күләмендә танылуын тәэмин итте. Дөньядагы 5000 телдән ЮНЕСКО 14 телне сайлап ала. Әлеге исемлек телләрнең дөнья халыкларына аңлаешлы булу ягыннан, катлаулы фикерләрне белдерә алу мөмкинлегенә карап төзелгән. Шулар арасында татар теле бар! Рәсәй Федерациясендә ике генә тел кергән: рус һәм татар теле генә. Ә безнең үзебездә генә дә 200дән артык тел бар бит. Төрки телләрдән бары тик татар теле генә кергән. Төрки телләрдән мөстәкыйль дәүләт булган Төркия бар. Анда 60 миллионнан артык кеше яши, ләкин төрек теле шушы 14 тел арасына кермәгән. Димәк, татар теле үзенең системасы, яңгырашы, сүзлек составының бай булуы белән башка телләрдән аерылып, өстен булып тора. Әлбәттә, без моның белән горурланабыз һәм безгә шул казанышны сакларга кирәк.

**көндә татар теленең, гомумкатламда куллану өчен, мөмкинлекләре бармы?**

– Телләр үссен өчен, берничә шарт бар. Иң кирәклесе – җәмгыятьтә телгә ихтыяҗ булу. Телнең башкара торган вазифалары күптөрле, киң булырга тиеш.

Беренче вазыйма – көндәлек тормышта кулланылуы. Бездә әле, шөкер, татар теле көндәлек тормышта киң кулланыла. Дөрес, борчыган нәрсәләр дә бар. Мәсәлән, ватаҗимерә булса да башка телдә сөйләшү күренешләре күзәтелә. Бигрәк тә өлкән буын кешеләренең дә балалары киң кулланыла торган телдә сөйләшкәч, аларга яраклашырга теләп, аларча сөйләшергә омтылу күренешләре бар. Ләкин моңа бирешмәскә кирәк.

Икенчесе – аның матур әдәбиятта кулланылуы. Чөнки әдәби теле, матур әдәбияты булмаган халыкның көндәлек сөйләм теле дә ярлы була. Телнең үсеше һәм сакланышы бары тик матур әдәбият әсәрләрендә генә булырга мөмкин. Мәсәлән, без бүген дә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрен укыйбыз һәм татар теленең нигезен тәшкил итә, дип саныйбыз икән, андагы бөтен сүз запасы – бүгенге көндә дә кулланылышта. Әгәр дә шушы әсәр булмаса без моны ничек саклар идек икән?!

Ә үсеше мәсьәләсенә килгәндә, ел саен, гасыр саен телебез камилләшә һәм үсә бара. Әнә шул Кол Гали әсәре, Алтын Урда ядкәрләре, Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел фәрадис», Сәиф Сараи әсәрләреме... Гасырдан-гасырга телдә үзгәрешләрне күзәтеп килергә мөмкин. Казан ханлыгына җитсәк, Өмми Камал, Мөхәммәдъяр әсәрләре. XIX гасырда без бөтенләй башка күренешкә тап булабыз, әдәби телнең төрекләшә баруы. Ул инде XX гасыр башына шактый гади халык аңламаслык хәлгә җиткән, ягъни әдәби тел белән халыкның гади сөйләм теле арасында бик нык аерма бар. Күрәсез, телдә нинди үзгәрешләр бара, ә инде күзәтә алабыз. Телне саклау һәм үстерүдә әдәбиятның мөһимлеген күрәбез.

Әлбәттә, телнең дәрәҗәсе һәм аның үсеше – тормыш-көнкүрештә бер, ә уку-укыту, тәрбия барышында, сәнгатьтә кулланылуы башкача һәм шул кулланылыш вакытында алар заманга туры китерелеп байый баралар.

Ә инде татар теленең бүгенге техник өлкәләрдә кулланылышына килгәндә, безнең зыялыларыбыз XX гасыр ахырында бик зур үрләргә җитеште. Татар телен техник яктан куллануга мөмкинлекләр бик күп. Менә инде ничә елдан бирле дөнья мәйданын әйләндереп алган интернет системада татар теленең кулланылышын күзәтәбез. Интернет программаларны татарчалаштыру, тәрҗемә итү – болар барысы да татар телен техник өлкәгә кулланылышка кертү күрсәткече. Бу, әлбәттә, башлангыч хәлдә генә әле, безгә әле аны үстерергә, камилләштерергә кирәк. Ләкин шунысы әһәмиятле – димәк, шундый даирәләрдә дә татар телен иркенләп кулланып була. Моңа бары тик мөмкинлекләр генә кирәк.

## Телнең киләчәге нинди?

**– Фоат абый, телебезнең киләчәген ничек күзаллыйсыз? Телне саклап калу өчен, без нинди чаралар күрергә тиеш?**

– Телебезне көнкүрештә генә түгел, ә әдәби әсәрләр, техник кулланылыш дәрәҗәсендә, фәнни даирәләрдә мөмкин кадәр күбрәк куллану. Кулланылышны тарайтмау, киметмәү. Киресенчә, көннән көн арттыру һәм кулланылыш даирәсен киңәйтү. Менә шунда инде аның бөтен яшәү яки яшәмәү мәсьәләсе.

Тагын бер мөһим мәсьәлә бар. Ул да булса – мәктәпләрдә татар телен укытуны тиешле дәрәҗәгә кую. Хәзер мәктәпләрдә татар телен укыту ата-аналарның гариза язуларына бәйле. Күпчелек ата-аналар үз балаларына татар телен укытуны сорап, таләп итеп гаризалар язалар. Аннары яңа уку елында ачылган «Адымнар» мәктәбе һәм шул мәктәпкә тәңгәл килерлек уку йортларының ачыла башлавы күңелдә канәгатьлек хисе тудыра. Димәк, телебезнең киләчәге халыкның үзеннән генә түгел, ә бәлки дәүләтнең татар телен әнә шундый юнәлешләрдә үстерүенә һәм машуңа юл тотуына да бәйле.

*«Безнең халкыбыз күп миллионлы һәм аның холкының һәм яшәү рәвешенең бик әһәмиятле үзенчәлеге бар: кая гына барса да, кайда гына яшәсә дә, үз теленнән ваз кичмәү»*

## «Имамнар да диктор кебек бит инде»

**– Имамнарга дикторлык серләрен белү ни дәрәҗәдә мөһим?**

– Дикторны, лекторны, укытучыны – без бит тел белән эш итәбез, тел ярдәмендә фикерләребезне белдерәбез. Имамнар да диктор кебек бит инде. Темалар гына төрле. Мәчетләрдә вәгазь сөйләгәндә дә, Коръән мәҗлесләрендә дин әһеле төп сөйләүче, шушы мәҗлесне алып баручы, аңа юнәлеш бирүче. Вәгазь сөйләргә бик нык әзерлек кирәк дип уйлыйм мин, чөнки алар берүк теманы гына күтәрмиләр. Һәр көнне нинди дә булса яңа темага әзерләнеп киләләр. Коръәнне белергә, сүрәләр, Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрен аңларга һәм аңлата белергә кирәк. Имамнар шулкадәр күп материалны карап, бер ноктага тезеп, аерым бер теманы ачарлык итеп әзерләнәләр.

Имам чыгышка гыйлем ягыннан никадәр генә әзерлекле булса да, халык алдына чыгып басар алдыннан, тел ягыннан әзерлек кирәк. Аларның үз сөйләм алымнары да бар. Мәсәлән, үткән заманны белдерүнең ике төре: билгеле үткән заман һәм билгесез үткән заман бар. Имамнар билгеле үткән заман белән сөйләшәләр. Анысы да миңа кызык тоела. Без алай сөйләшмибез. Әгәр игътибар иткән булсагыз, имамнар «Мөхәммәд пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте», – диләр. Әйткән димиләр, чөнки «әйткән» дип сөйләү билгесезлекне белдерә. Әйтерсең лә имам кемнәндер ишеткәнне генә сөйли. Нәтиҗәдә, дин әһеленә карата ышаныч тумас иде. Билгеле формада сөйләгәндә, Мөхәммәд пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм яки аның якын кешеләре әйткәнне имамнар үзләре ишетеп торган кебек була. Мин моны имамнарга гына хас үзенчәлекле бер сөйләм дип кабул итәм. Үзенә күрә бер матур сөйләм ул.

## Татар теле интернет теле була аламы?

**– Теләсә кайсы тел, тел буларак яшәсен өчен, авылда, өйдә генә түгел, ә фәнни, һөнәри өлкәләрдә дә кулланылуы кирәк. Бүгенге**

Г.Кандалый, Г.Тукай, Г.Камалдан башлап чын халыкчан телгә әйләнеп кайту һәм XX гасырда аның искиткеч зур югарылыкка күтәрелә, ягъни әдәбият ярдәмендә без тел торышының үсешен (эволюциясен)

*«Дин әһелләребез телне саклауга бик нык ярдәм иткән, чөнки гомер-гомергә татар телендә, халыкның үз телендә әнә шул катлаулы әйберләрне мөмкин кадәр үтемле итеп җиткерә килгәннәр»*

■ Әңгәмәне **Ленар ХАММАТОВ** оештырды

# Рамазан аеның фазыйләте

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән бүләкләгән Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак расүле, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә безгә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

***«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды. Бәлки, [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»***

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Рамазан аенда һәр көн ураза тоту, ягъни таң яктылыгы җәелгән вакыттан башлап, кояш батканчыга кадәр ашамый, эчми һәм якынлык кылмый тору – балигъ һәм акыллы булган һәрбер мөэмин кешегә фарыз.

Аллаһы Тәгалә: «Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек», дип әйтә, ягъни безгә кадәр булган барча халык та уразалы булганнар, хәтта археологларның тикшерүләренә караганда, безгә кадәр уразасыз халык яшәмәгән, диләр. Сәгыйть бине Җөбәер болай дип әйткән: «Безгә кадәр исламның әүвәлге вакытында да уразаны кичтән алып икенче кичкә кадәр тоталар иде», ягъни безнеңчә әйткәндә, бер тәүлек. Әмма инде шушы аять иңгәч бу йола туктатылды.

Шушы аятькә тагын күз салсак, Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә: «Бәлки, тәкъвалык ияләреннән булырсыз». Әмма «ураза тотып, әлбәттә, тәкъвалы буласыз», димәгән, чөнки кешенең һәртөрле гөнаһтан, гайбәттән, харамга күз төшерүдән, сүгенүдән, талашулардан һ.б. саклана аламы яки юкмы икәне үзеннән тора.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр дә кеше бозык сүзләрдән, ялганнан, гайбәттән тыела алмаса, Аллаһы Тәгалә аның ашау-эчүне ташлавына мохтаҗ түгел», – дип әйткән.

Шуңа күрә мөселман игелекле, күркәм әхлаклы, хәерле сүзле булырга тиеш.

Шулай ук Раббыбыз Сөбеханәһү вә Тәгалә болай дип әйтә:

***«Рамазан ае – аңарда кешеләр өчен һидаять, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр, хакны ялганнан аерган Коръән иңдерелгән [ай]. Сездән берәү Рамазан аена ирешсә, аны ураза тотып үткәрсен...»***

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Аллаһының ураза тотарга биргән әмере: ирләргә, хатыннарга, яшьләргә, картларга, байларга, ярлыларга, патшаларга, эшчеләргә, укучыларга һәм хәрбиләргә. Эшнең авырлыгы, тормышның мәшәкатьле булуы, балаларның күплеге, яшьләрнең мәктәптә яки югары уку йортларында укулары һәм бәла-каза килүләр, ураза тотмаска гозер була алмыйлар. Фәкать ятып чирләгән, мәшәкатьле озын сәфәрдә булган, картлык зәгыйфьлегенә ирешкән, тоткында булган һәм йөкле, хәезле хатыннар – болар гозерле булалар. Картлык зәгыйфьлегенә ирешкән кеше һәм сәламәтлекне торган чирле кеше, болар көчләре җитмәү сәбәпле ураза тотмыйлар һәм каза да кылмыйлар. Маллары булса, фидия бирәләр.

Әлеге аятьнең дәвамы бар:

***«...ләкин кем [ураза тота алмаслык дәрәҗәдә] авыру яки сәфәрдә булса, башка санаулы көннәрне [тотарга тиеш]. Аллаһы сезгә җиңеллек тели, сезгә авырлык теләми, [ураза тотарга кирәкле көннәр] санын тутырырсыз, һәм, сезгә туры юлны күрсәткәне өчен, Аллаһыны олыларсыз [дип]. Бәлки, [Аллаһының хисапсыз нигъмәтләренә, бигрәк тә шушы рөхсәтләренә] шөкер итүчеләрдән булырсыз!»***

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Шушы аятьтән аңлашылганча, Коръән Рамазан аенда иңә башлаган, шуңа күрә Рамазан аенда Коръән уку мөстәхәб һәм савабы да артыграк.

Әл-Багави дигән галим түбәндәге сүзләрне әйткән: «Дөреслектә, «Рамазан» дигән сүз «Рамдаа» дигән сүздән алынган, ягъни кыздырылган ташлар мәгънәсендә, чөнки алар кызу көннәрдә ураза тотканнар». Ул замандагы гарәпләр берәр айга исем бирергә теләгәндә, алар беренче чиратта вакыйгаларга яки фасылларга карый торган булганнар, әмма Рамазан ае кызу көнгә туры килгәч, алар ул айга «Рамазан», дип исем биргәннәр. Икенче бер галим: «Ул айны, гөнаһларны яндырганга күрә, «Рамазан» дип атадылар», – дип әйткән.

Рамазан уразасы икенче һиҗри елда фарыз була. Рамазан уразасы динебездә зарури, шуңа күрә аны инкяр иткән кеше көферлеккә төшә.

Рамазан уразасы турында күп кенә хәдисләр риваять ителә, шуларның кайберәүләрен карап үтик.

Әбү Һөрайрадан Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләре риваять ителә: «Рамазан ае кергәч, җәннәт ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла, шәйтаннар богаулана», – диде. Күпләребезнең сизгәне бардыр, башка айлардан аермалы буларак, Рамазан аенда ураза тоту аеруча җиңел һәм гөнаһлар да аз кылына.

Хәдис дәвамында Аллаһы Тәгаләнең әлеге сүзләре тапшырыла: «Әй хәерлегә омтылучы! Аллаһыга якынай! Әй начарлыкка омтылучы! Гөнаһыңнан тукта! Аллаһы һәр төнне бер ураза тотучыны җәһәннәмнән коткарыр».

Дәвам итеп Аллаһы Тәгалә болай дип әйтер: «Гафу сораучы бармы, гөнаһларын гафу итәрмен! Берәр ихтыяҗың бармы, сораганыңны бирермен! Тәүбә кылучы бармы, тәүбәләрен кабул итәрмен!» Һәм шушы мөрәҗәгать таң атканчы дәвам итәр. Һәм Аллаһы Тәгалә һәркөнне, һәр ифтар вакытында меңләгән ураза тотучы мөселманнарны җәһәннәм утыннан коткарыр» (имам Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан).

Әй кардәшләрем! Шушы форсаттан мәхрүм кала күрмәгез, чөнки тагын бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ни үкенеч шул кешегә, Рамазан үтеп китеп тә, гөнаһлары гафу ителмәсә», – дигән.

Сәлмән Әл-Фәриси Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәгъбан аеның соңгы көнендә сөйләгән вәгазен риваять итә: «Әй кешеләр! Сезгә бөек ай якынлашып килә, ул айда мең айдан да хәерлерәк булган Кадер кичәсе бар һәм Аллаһы Тәгалә бу айда уразаны сезгә фарыз итте, ә тәравих намазын сөннәт итте. Кем бу айда бер изгелек кылса, фарыз гамәлне үтәгән кебек булыр, ә кем фарыз гамәлне үтәсә, җитмеш фарызга тиң булыр. Рамазан – сабырлык ае, ә сабырлыкның нәтиҗәсе – җәннәт. Рамазан ае – уртаклашу ае. Ул айда мөселманның ризыгы киңәер, кем уразалы кешегә авыз ачтырса, ураза тоткан кешенең әҗерен алыр, гөнаһысы гафу ителеп, үзен уттан саклар». Шуннан соң сәхабәләр: «Йә Расүлуллаһ! Һәрберебез дә ураза тотучыга авыз ачтырырлык ризык таба алмыйбыз», – диделәр. Пәйгамбәребез җавап итеп: «Кем ураза тотучыга бер йотым сөт яки су яки бер бөртек хөрмә булса да бирсә, Аллаһы аның әҗерен шиксез бирер. Ә кем инде ураза тотучыны тукландырып ашатса, аның бөтен гөнаһлары ярлыканыр, Аллаһы аны үзенең чишмәсеннән су эчертер вә шуннан соң ул беркайчан да сусамас һәм Аллаһы Тәгалә аңа ураза тотучы кешенең әҗерен биреп, ураза тотучының да, аңа карап әҗерен киметмәс», – дип әйткән.

Тагын бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Рамазан аеның беренче ун көне – рәхмәт, икенче ун көне – мәгъфирәт, өченче ун көне – җәһәннәмнән котылу ае. Кем бу айда үзенең малын сарыф итсә, Аллаһы аны уттан саклар».

Бу айда дүрт әйберне эшләргә тырышыгыз: икесеннән сез Раббыгызның ризалыгына ирешерсез, ә калган икесенә сез үзегез мохтаҗдыр. Раббыбызның ризалыгына ирештерә торган беренче ике гамәл – ул да булса «Ләә иләәһә илләллаһу», ягъни «Аллаһыдан башка илаһ юк», дип даими шушы кәлимәне әйтү һәм истигъфар кылу, ә сез мохтаҗ булган гамәл: ул да булса Аллаһыдан даими җәннәтне эстәү һәм җәһәннәмнән сыгыну.

Пәйгамбәребез бер кодси хәдистә болай дигән: «Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә: «Адәм баласы кылган һәр гамәл үзе өчен, уразадан кала, чөнки ураза Минеке һәм әҗерен дә Үзем бирермен», – диде (имам Бохари, имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

Никадәр гүзәл гыйбадәт ул ураза! Аллаһы аны Минеке дип, безне шатландырды, чөнки ураза рияданерак булган бердәнбер гамәл. Ураза тотасыңмы, юкмы – Аллаһыдан кала беркем дә белә алмый, гәрчә син үзеңне уразалы дисәң дә.

Инде йомгаклап Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер гүзәл сүзен язып үтик. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ураза тотучы кешенең ике шатлыгы бар: берсе авыз ачкан вакытта, ә икенчесе, гөнаһыбыз гафу ителгән хәлдә Кыямәт көнендә Аллаһы белән очрашканда», – дип әйткән.

Аллаһы Тәгалә күңелләребезгә иман, тәкъвалык бирсен. Берберебезгә ярату, берләшүне кире кайтарып, урамда да, өйдә дә, мәчеттә дә, дөньяда да, үлгәч тә, Аллаһы Тәгалә мөселман булып калырга насыйп итсен. Аллаһы Тәгалә уразаларыбызны кабул әйләп, гөнаһларыбызны гафу итсә иде. Әмин!

■ **Тимергали хәзрәт ЮЛДАШЕВ,**
«Саләх» мәчете имам-хатыйбы

# Уразаның әһәмияте

***Рамазан аенда ураза тоту Ислам диненең өченче нигезе булып тора. Ураза тоту Һиҗрәтнең икенче елыннан башлап фарыз булган. Ураза тоту – таң атканнан алып кояш баеганчыга тикле ашау-эчүдән һәм җенси якынлыктан тыелып торуны аңлата.***

Мөселманнар Рамазан аен изге ай дип хөрмәт итәләр. Нәкъ менә шушы айда Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә пәйгамбәрлек иңдерелгән һәм шуның белән Ислам диненең яңарышы башланган. Коръән дә шул изге вакытта иңдерелә башлаган. Мең айдан хәерлерәк булган Кадер кичәсе Рамазанга туры килә. Әлеге айда мөэминнәр уразаларын тоталар. Ураза кешеләрне гөнаһлардан арындыра, явыз теләкләрдән һәм яман гамәлләрдән аларны тыеп кала.

**Ураза тоткан кешегә түбәндәге эшләр сөннәт санала:**

1) таң атканчы төнлә торып сәхәр ашау;

2) ураза тотып нәфесне гөнаһлы эшләрдән тыюны ният кылу;

3) кәсептән бушаган вакытларда дини китаплар уку;

4) кояш баегач, ахшам намазын укыганчы авыз ачу.

**Уразада көндезен 10 төрле эшне кылу мәкруһ санала:**

1) файдасыз сүзләр сөйләү;

2) әдәпсез сүзләр сөйләү;

3) суга чумып коену;

4) ризык һәм сагыз чәйнәү;

5) берәр азыкка телне тидереп татып карау;

6) авыздан үбү;

7) ифтар кылмыйча ике көн рәттән ураза тоту;

8) нинди дә булса бер гөнаһлы гамәл кылу;

9) авыруыңның артачагын белә торып ураза тоту.

10) сатып алыначак малны татып карау;

**Түбәндәге 10 төрле эшне башкару дөрес санала:**

1) балага ризык чәйнәп бирү;

2) күзгә сөрмә тарту;

3) мыек һәм иренне майлау;

4) тешләрне пакьләү;

5) кан алдыру;

6) сөлек салдыру;

7) комган белән госел коену;

8) сабын белән юыну.

## Түбәндәге өч төрле эш уразаны боза:

1) борчак кадәр генә булса да берәр ризык яки дару йоту;

2) бер тамчы кадәр генә булса да су яки дару йоту;

3) якынлык кылу.

Рамазан уразасын үз ихтыяры белән бозган кешегә һәркөн урынына бер көн каза кылу һәм бозган өчен кәффарәт кылу фарыз була.

Ураза кәффарәте өчен дөньяда коллар бетеп җитмәгән булса, берәр колны азат итеп, колларны бетерергә тиеш була. Әгәр кол табылмаса яки аны сатып алырга байлык җитмәсә, 60 көн тоташтан ураза тоту тиеш була. Әгәр дә зәгыйфьлек сәбәпле 60 көн ураза тотарга куәт җитмәсә, 60 фәкыйрьне туярлык итеп ашату кирәк була.

Ураза тоткан кеше хаталык белән бераз аш яки су йотса, бугазына кар яки яңгыр тамчылары керсә, авыз тутырып косса; таң аткан булса да, таң атмаган дип белеп сәхәр ашаса, кояш батмаган булса да, кояш баткан дип белеп авыз ачса яки якынлыктан башка җөнеб (госелсез) булса, уразасы бозыла. Андый кешегә Рамазан ае үткәннән соң уразасын каза кылу тиешле була, ә кәффарәт тиеш түгел. Уразасы көндез бозылган кеше, кояш батканчы, уразалы кебек ашамыйэчми торырга тиеш.

Бер кешенең бугазына тузан, туфрак, йон, төтен керсә; бер кеше төкреген, какрыгын яки теш арасында калган ризык кисәген йотса; уразалы икәнен онытып ашап-эчсә яки якынлык кылса, ул кешенең уразасы бозылмый.

Хәез һәм нифас белән гозерле булган хатыннарга ураза тоту дөрес түгел. Алар Рамазан аенда тотылмый калган уразаларын Рамазаннан соң каза кылырга тиешләр.

Ураза тотарга көче җитмәгән бик зәгыйфь, карт кеше ураза тотмаса, һәркөннең уразасы урынына бер фәкыйрьне туярлык итеп ашатырга яки ризык алырга җитәрлек акча бирергә тиеш була. Әгәр Рамазан аеннан соң шул карт сәламәтләнсә, калган уразаларын каза кылырга тиеш. Йөкле яки бала имезә торган хатыннар, ураза тоткан вакытта, үзләренә яки балаларына зыян килүдән һәм хаста кешеләр үзләренең авырулары көчәюдән курыксалар, ураза тотмасалар да дөрес була. Аларның һәркайсы калган уразаларын Рамазаннан соң каза кылырга тиеш була. Рамазан аенда мосафир булган кешегә дә ураза тотмау рөхсәт ителә. Сәфәреннән кайткач, аңа да калган уразаларын каза кылырга кирәк.

### Ният

Сәхәр ашаганнан соң ураза өчен таң атканчы ният кылу – мөстәхәб.

Ураза тоту өчен күңел белән ният кылына. Тел белән һичбер сүз әйтмичә, күңелдән «иртәгә ураза тотачакмын» дип уйлау да дөрес.

Ураза тотар алдыннан түбәндәге сүзләрне (гарәпчә) укып, тел белән ният кылу мөстәхәб санала:

**Нәүәйтү ән әсуумә саумә шәһри рамадаанә минәл-фәҗри иләлмәгъриби хаалисан лилләәһи тәгаалә.**

Мәгънәсе: *«Аллаһы Тәгалә өчен, ихласлык белән таң вакытыннан башлап, кояш батканчыга кадәр Рамазан уразасын тотарга ният кылдым».*

### Ифтар

Кояш баткач нинди дә ризык, тоз яки су белән ифтар кылу, ягъни авыз ачу – сөннәт. Хөрмә кебек татлы җимешләр белән ифтар кылу – мөстәхәб.

Ифтардан соң (авыз ачканнан соң) түбәндәге дога укыла:

**Аллааһуммә ләкә сумтү вә бикә әәмәнтү вә галәйкә тәүәккәлтү вә галәә ризкыйкә-фтартү фәгъфирлии йәә гаффәәрү мә каддәмтү вә мәә әххартү.**

Мәгънәсе: *«Аллаһым, шушы уразамны Синең өчен тоттым, Сиңа гына иман китердем һәм Сиңа тәвәккәл иттем. Синең ризыгың белән авыз ачам. Әй гөнаһларны гафу итүче Аллаһым, минем әүвәлге гөнаһларымны да, соңгы гөнаһларымны да ярлыка».*

### Тәравих намазы

Рамазан аенда ястү намазыннан соң тәравих намазы укыла. Тәравих намазын уку сөннәт санала. Пәйгамбәребез җәмәгать җыеп, тәравих укыган һәм өммәтеннән дә тәравих укуны таләп иткән. Тәравих намазын 20 рәкәгать итеп уку сөннәт. Аны икешәр рәкәгать итеп, һәр ике рәкәгатьтән соң сәлам биреп тәмамлап, яки дүртәр рәкәгать итеп, һәр дүрт рәкәгатьтән соң сәлам биреп тәмамлап укырга мөмкин. Тәравих намазын мәчеттә җәмәгать белән уку саваплырак. Һәр дүрт рәкәгатьтән соң тәравих тәсбихен әйтү бик саваплы гамәл. Тәравих тәсбихенең укылышы: «Сүбхәәнә ҙил-мулки вәл-мәләкүүт. Сүбхәәнә ҙил-гыйззәти вәл-гәҙәмәти вәл-кудрати вәл-кибрийәә'и вәлҗәбәрүут. Сүбхәәнәл-мәликилхәййил-ләҙи ләә йәмүүт. Сүббүүхүн куддүүсүр-раббүнәә вә раббүлмәләә'икәти вәррүух. Ләә иләәһә илләллаahү нәстәгъфируллааh. Нәс'әлүкәл-җәннәтә үә нәгуузү бикә минән-нәәр».

Мәгънәсе: Җирдәге һәм күктәге мәхлукатның хуҗасы булган Аллаһы Тәгаләне данлыймын. Көч, кодрәт һәм бик олуглык иясе булган Аллаһы Тәгаләне данлыймын. Бөтен галәмнең патшасы һәм беркайчан үлмәячәк, һәрвакыт терек булучы Аллаһы Тәгаләне данлыймын. Ул Аллаһы Тәгалә бөтен кимчелекләрдән бик пакь һәм мөкаддәс Зат, бөтен фәрештәләрнең һәм Җәбраил фәрештәнең Раббысы. Бер Аллаһы Тәгаләдән башка илаһи Зат юк. Без гөнаһларыбызның ярлыкавын сорыйбыз. Йә, Раббым, без Синнән җәннәтне сорыйбыз һәм тәмугтан Сиңа сыенабыз.

### Кадер киче

Рамазан аеның соңгы ун көне эчендә бер мөбарәк кичә бар. Ул Кадер киче. Кадер кичендә бер бәндә ураза хәлендә, уяу торып, намаз укып, Аллаһыдан дога кылып сорый торган булса, һичшиксез, догалары кабул булыр. Бу кичтә Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләнең барлык рәхмәт фәрештәләре җир йөзенә төшеп, дога кылучы бәндәләрнең догаларын кабул итүне Аллаһыдан үтенәләр, аларның гөнаһларының гафу ителүен сорап, Аллаһыга ялваралар. Бу Кадер кичендә гамәлгыйбадәтләребезне, тәүбә-истигъфарларыбызны, дога-тәсбихләребезне күп итеп кылуыбыз киңәш ителә. Бу кичтә Аллаһыга нәфел намазларыбызны да күп итеп кылыйк, булдыра алганнарыбыз тәсбих намазы укыйк. Бу намаз бик тә саваплы намазлардан булып санала.

### Фидия

Рамазан аенда ураза тота алмаган кешеләр уразаларын башка айларда тота ала, уразаны бөтенләй тота алмаганнар фидия садакасы түләргә тиеш була. Фидия – ураза тотмаган көннәр өчен бирелә торган садака. Фидия акчалата түләнергә мөмкин. Сәламәтлек торышына бәйле рәвештә ураза тоту мөмкинлегенә ия булмаган һәм аны башка вакытта да каза кылып үти алмаучылар өчен бу елда тотылмый калган һәрбер көне өчен 200 сум күләмендә фидия билгеләнде.

### Фитыр

Фитыр садакасы бирү һәр мөселманга да вәҗиб гамәлләрдән санала. Фитыр садакасы мохтаҗларга бирелә. Фитыр садакасын мөселман булмаганнардан һәм фәкыйрьләрдән тыш, бар кеше дә бирергә тиеш. Фитырны гаилә башлыгы барлык гаилә әгъзалары һәм аның тәрбиясендә булган кешеләр өчен үзенең кеременнән түли. Ир бала балигъ булуга, фитырны үзе өчен үз кеременнән түләргә омтылырга тиеш. Андый мөмкинлеге булмаган очракта, бу бурыч гаиләдәге башка ир-атлар өстенә төшә.


Бу елда фитыр садакасы түләү өчен нисаб күләме – 36 000 сум (көмеш буенча), фитыр садакасы күләме (зәкят әлфитыр – Ураза тәмамлану уңаеннан бирелә торган садака) – арпа белән исәпләгәндә – 100 сум, йөзем буенча – 700 сум. Зәкят түләү өчен нисаб күләме – 310 000 сум (алтын буенча).

**«Хозур»** редакциясе

# Намазга өйрәнәбез

*Намаз – мөселманның бу тормышта аңа Аллаһының биргән барлык нигъмәтләре өчен илтифатын, хөрмәтен күрсәткән гамәле. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ахирәттә иң беренче булып намаз уку-укымау турында соралачак», – дип әйткән.*

*Алдагы санда без укучыларыбызны намаз уку тәртибе белән таныштыра башлаган идек. Бу санда хатын-кызларның өйлә намазының 4 рәкәгать фарызын уку тәртибен карап үтик.*



**1 рәкәгать**

Кыйблага карап, аяк араларын 4 бармак киңлеге калдырып басабыз, әмма шул киңлектән арттыру киңәш ителми. Аннан ният әйтелә: **«Аллаһы ризалыгы өчен, өйлә намазының 4 рәкәгать фарызын үтәргә ният кылдым, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, халисан лилләһи Тәгалә».**

**«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән кереш тәкбире әйтелә. Хатын-кызлар уч төпләрен кыйблага каратып, бармакларын ачмый гына, кулларын иңбашы турысына күтәрәләр. Аннан соң уң кулны сул кул өстенә куеп, күкрәк турысында тоталар.

Кыямда **«Сәнә»** догасын укыйбыз: **Сүбхәәнәкәл-лааһуммә вә бихәмдикә вә тәбәракәс-мукә вә тәгааләә җәддүкә вә ләә иләәһә гайрүк.**

Аннан соң **«Фатиха»** сүрәсе укыла: **Әгүүҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.**

***Әлхәмду лилләәһи раббил гааләмиин. Әр-рахмәәнир-рахиим. Мәәлики йәүмиддиин. Ийәәкә нәгъбуду вә ийәәкә нәстәгыйн. Иһдинәс-сыйрааталь мүстәкыйм. Сыйрааталь ләҙиинә әнгамтә галәйһим. Гайрил мәгъдүүби галәйһим үәләәд-дааалиин*** («Әәмин» эчтән генә әйтелә).

**«Фатиха»** сүрәсеннән соң Коръәннән берәр сүрә укыйбыз, мәсәлән **«Кәүсәр»** сүрәсен: **Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Иннәә әгътайнәәкәл кәүҫәр, фәсалли лираббикә үәнхәр, иннәә шәәни-әкә һүәл әбтәр.**

**«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән рөкүгъка иеләбез (билдән бөгеләбез). Иелгән килеш: **«Сүбхәәнә Раббийәл-гаҙыйм»,** – дип 3 тапкыр әйтелә.

Мәгънәсе: «Олуг Раббымны пакь дип таныйм».

(Хатын-кызларның тезләре һәм аркалары бераз (тулаем түгел) бөгелә, бармак араларын ачмый гына кулларын тезләренә куялар).

Торайганда **«Сәмигаллаһу лимән хәмидәһ»** дип әйтелә.

*Мәгънәсе:* «Аллаһы Тәгалә Үзен мактаучыларны ишетә».

Турайгач, **«Раббәнә ләкәл хәмде»** дип әйтәбез.

*Мәгънәсе:* «Раббыбыз, барча мактаулар Сиңа гына тиешле».

Шуннан соң **«Аллаһу әкбәр»** дип әйтеп сәҗдәгә китәбез.

Җиргә элек тез башлары, аннары кулларның учлары, аннары маңгай һәм борын тидерелә. Сәҗдәдә баш ике кулның арасында була, аяклар җирдән аерылмыйлар, күзләр борын очына карыйлар.

Сәҗдәдә: **«Сүбхәәнә Раббийәл-әгъләә»,** – дип 3 тапкыр кабатлана.

*Мәгънәсе:* «Бөек Раббымны пакь дип таныйм».

(Хатын-кызлар сәҗдәне кысылыбрак кыла, терсәкләре җиргә таяна, аяк бармаклары кыйбла тарафына юнәлтелә).

**«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән маңгайны җирдән аерып, тез өстендә утырып торабыз. Хатын-кызлар ике аякны да уң якка чыгарып куеп, сул аякка утыралар, аяк бармаклары кыйблага карап тора.

**«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән икенче сәҗдә кылына: **«Сүбхәәнә Раббийәл-әгъләә»,** – дип 3 тапкыр әйтәбез.

*Мәгънәсе:* «Бөек Раббымны пакь дип таныйм».

**«Аллаһу әкбәр»** дип икенче рәкәгатькә торабыз. Кыямда куллар күкрәкнең өске өлешендә бәйләнеп куела.

**2 рәкәгать**

Аягүрә баскан килеш, башта **«Бисмилләһ», «Фатиха»** сүрәсе укыла: **Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.**

***Әлхәмду лилләәһи раббил гааләмиин. Әр-рахмәәнир-рахиим. Мәәлики йәүмиддиин. Ийәәкә нәгъбуду вә ийәәкә нәстәгыйн. Иһдинәс-сыйрааталь мүстәкыйм. Сыйрааталь ләҙиинә әнгамтә галәйһим. Гайрил мәгъдүүби галәйһим үәләәд-дааалиин*** («Әәмин» эчтән генә әйтелә).

**«Фатиха»** сүрәсеннән соң Коръәннән берәр сүрә укыйбыз, мәсәлән **«Ихлас»** сүрәсен: **Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Куль һү-уәл-лааһу әхәде. Әл-лааһүс-самәде. Ләм йәлиде вә ләм йүләде. Вә ләм йәкүл ләһүү куфу-үән әхәде.**

**«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән рөкүгъ кылына: **«Сүбхәәнә Раббийәл-гаҙыйм»,** – дип 3 тапкыр әйтелә. Рөкүгътан турайганда түбәндәге дога әйтелә: **«Сәмигаллаһу лимән хәмидәһ».** Турайгач, **«Раббәнә ләкәл хәмде»** дип әйтәбез.

**«Аллаһу әкбәр»,** – дип әйтеп сәҗдәгә китәбез: **«Сүбхәәнә Раббийәл-әгъләә»,** – дип 3 тапкыр әйтәбез. **«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән маңгайны җирдән аерып, тез өстендә утырып торабыз. **«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән икенче сәҗдә кылына. Сәҗдәдә: **«Сүбхәәнә Раббийәл-әгъләә»,** – дип 3 тапкыр кабатлана.

**«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән кагъдәгә утырабыз. Куллар тез өстенә куела, күзләр тез башларына карый. Хатын-кызлар ике аякны да уң якка чыгарып куеп, сул аякка утыралар, аяк бармаклары кыйблага карап тора.

Утырган килеш иң элек **«Тәшәһһүд»** укыйбыз: **Әт-тәхиййәәту лилләәһи вәс-саләүәәту вәт-таййибәәт. Әс-сәләәму галәйкә әййүһән-нәбиййу вә рахмәтул-лааһи вә бәракәәтүһ. Әс-сәләәму гәләйнәә вә галәә гибәәдил-ләәһиссаалихиин. Әшһәду әл-ләә иләәһә илләл-лааһу. Вә әшһәду әннә Мухәммәдән габдүһүү вә расүүлүһ.**

Аннан соң **«Аллаһу әкбәр»** дип әйтәбез дә, өченче рәкәгатькә басабыз.

**3 рәкәгать**

Кыямда басып торганда, **«Бисмилләһ»** әйтеп, **«Фатиха»** сүрәсен укыйбыз.

**«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән рөкүгъка бөгеләбез. Рөкүгъта: **«Сүбхәәнә Раббийәл-гаҙыйм»,** – дип 3 тапкыр әйтелә. Турайганда: **«Сәмигаллаһу лимән хәмидәһ»** дип әйтелә. Турайгач, **«Раббәнә ләкәл хәмде»** дип әйтелә.

**«Аллаһу әкбәр»,** – дип әйтеп сәҗдәгә китәбез. Сәҗдәдә: **«Сүбхәәнә Раббийәл-әгъләә»,** – дип 3 тапкыр кабатлана. **«Аллаһу әкбәр»** дип, сәҗдәләр арасында утырып торабыз.

**«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән икенче сәҗдә кылына: **«Сүбхәәнә Раббийәл-әгъләә»,** – дип 3 тапкыр кабатлана.

**4 рәкәгать**

**«Аллаһу әкбәр»** дип әйтелә (дүртенче рәкәгатьне укырга әзерләнелә) һәм кыямда (басып торганда) куллар күкрәкнең өске өлешендә бәйләнеп куела.

Басып **«Бисмилләһ»** әйтеп, **«Фатиха»** сүрәсен укыйбыз. **«Аллаһу әкбәр»** сүзләре белән рөкүгъка иеләбез: **«Сүбхәәнә Раббийәл-гаҙыйм»,** – дип 3 тапкыр әйтәбез. Турайганда **«Сәмигаллаһу лимән хәмидәһ»,** – дип әйтәбез.

Тулаем тураеп беткәч, **«Раббәнә ләкәл хәмде»** дип әйтәбез. **«Аллаһу

**әкбәр»**, – дип әйтеп сәҗдәгә китәбез.

Сәҗдәдә: **«СүбехәәнәРаббийәл-әгъләә»**, –дип 3 тапкыр кабатлана.

**«Аллаһү әкбәр»** сүзләре белән маңгайны җирдән аерып, тез өстендә утырып торабыз.

**«Аллаһү әкбәр»** дип икенче сәҗдә кылабыз.

Сәҗдәдә: **«Сүбехәәнә Раббийәл-әгъләә»**, – дип 3 тапкыр кабатлана.

**«Аллаһү әкбәр»** сүзләре белән сәҗдәдән күтәрелеп тезгә утырабыз.

Утырган килеш **«Тәшәһһүд»**, **«Салават»** һәм **«Раббәнә»** догалары укыла. Шуннан соң ике якка сәлам бирелә.

Башны уң якка борып, **«Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллааһ»**,– дип, сәлам бирәбез.

Шулай ук башны сул якка борып, **«Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллааһ»**, – дип, сәлам бирәбез.

**«Әстәгъфируллаһ, әстәгъфируллаһ, әстәгъфируллаһ»**, – дип әйтеп, сәлам догасы укыла: **Аллаһүммә әнтәс-сәләәмү вә минкәс-сәләәмү, тәбәрактә йә ҙәл җәләәли вәл икрам**.

*Мәгънәсе:* «Аллаһым! Син һәрбер бәлаләрдән саклаучысың, һәм бөтен иминлек бары тик Синнән генә. Ий Аллаһым! Син – Мөбарәк затсың, Олуглык һәм Рәхмәт иясесең Син!»

Моннан соң учларыбыз белән битне сыпырып куябыз. Өйлә намазының 4 рәкәгать фарызы шул рәвешле тәмамлана.

**«Намаз уку тәртибе»** китабыннан

# Коръәнне матур итеп уку



Коръән җир йөзендәге иң матур китап. Аннан да матуррак китап юк. Шулай ук Коръәннең сүзләре дә барлык сүзләрдән дә иң гүзәле. Алардан да күркәмрәк сүзләр юк һәм без – мөселманнар Аллаһының Изге Китабын матур итеп укырга тырышырга тиеш. Моннан без канәгатьлек һәм шатлык хисләре кичерәбез.

Баштан Коръәни Кәримдә тамгалар булмаган. Безнең динебез әкренләп җир йөзе буйлап тарала башлагач, Ислам динен кабул итүчеләрнең саны арткан. Һәм Исламны яңа гына кабул итүче кешеләр Коръәни Кәримне укыганда кайбер авырлыклар белән очрашканнар. Моны хәл итү өчен, Коръәни Кәримгә билгеле бер тамгалар кую ихтыяҗы барлыкка килгән. Һәм бу Аллаһының Изге Китабын укуны җиңеләйткән.

Коръәнне матур итеп уку – ул сәнгать. Аны матур итеп, көйләп уку әйләнә-тирәдәге тыңлаучыларга да тәэсир ясый. Әлбәттә инде, һәрберебез дә моны булдыра алмый. Әмма без булдыра алганча матур һәм дөрес итеп, ихлас күңелдән укырга тиешлебез.

Коръәнне укый башлар алдыннан тәһарәт алырга, аннары: «Әгууҙү билләһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим», сүзләрен әйтергә кирәк. Коръән укыган вакытта без рухи яктан пакьләнәбез, матураябыз.

### Тәэсир ясый торган Китап

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәр кич Мәккәдә үзенең ишегалдында матур тавыш белән Коръән укый торган иде. Бу шулхәтле кешеләргә тәэсир ясый торган булган ки, хәтта Мәккә мөшрикләре дә төнлә яшерен рәвештә Расүлебезне тыңларга килә торган булганнар. Берьюлы өч мәшһүр мәккәле кеше яшеренеп кенә Пәйгамбәребезнең укыганын тыңларга килгән. Тыңлап бетереп, өйләренә таралышканда очраклы рәвештә берләрен күреп алганнар. Әмма һич кенә дә Коръән тыңларга килгәннәрен бер-берләренә сиздермәгәннәр. Тик барысы да көн кебек ачык булган: Коръәни Кәримне инкяр итүче кешеләр яшеренеп кенә аны тыңлар өчен җыелган. Бу бик тә гаҗәп хәл! Аны ничек тә булса аңлатып буламы?! Бу өч кеше үзара аларны берәрсе күрергә мөмкинлеген сөйләшкәннәр һәм башка килмәскә дип сүз куешканнар. Әмма икенче көнне кич белән, тыелып кала алмыйча, яңадан Коръәни Кәримне тыңларга җыелганнар. Күз алдыгызга гына китерегез, хәтта мөшрикләргә дә Коръән шундый нык тәэсир ясаган.

Ә Коръәни Кәримнең бөекләгән, пакьләгән аңлаган кешегә ул тагын да көчлерәк тәэсир ясый, чөнки ул кеше Коръән аятьләренең җанга һәм тәнгә шифа иканлегенә ихлас күңелдән ышана.

■ Сәхифәне **Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде



## ТР МДНнең «Хозур» нәшрият йортыннан яңа китап – «Зубдатуль-Бухари»




«Сахих Әл-Бохари» – алты төп сөнни хәдис җыентыгының берсе. Сезнең алдыгызда әлеге җыентыкның кыскартылган варианты – **«Зубдатуль-Бухари»**. Җыентык галим Гомәр Дияуддин Әд-Дагыстани тарафыннан төзелде Шәех Гомәр Дияуддин дин фәннәренең төрле тармаклары: хәдис, Ислам тарихы, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сирасы (тормыш юлы), суфичылык, гакыйдә, Коръән рецитациясе һ. б. буенча егермеләп кыйммәтле әсәрнең авторы булып тора. Бу әсәрләрнең күбесе Дагыстанда һәм чит илләрдә, аерым алганда, Төркиядә басылып чыккан.

Китапта рус телендәге тәрҗемәсе белән мең ярымнан артык хәдис урын алган. Коръәни Кәримнән соң икенче урында әлеге хезмәт («Сахих Әл-Бохари») динебезнең фундаменталь чыганагы булып тора. Шуңа күрә әлеге китап мөселманнарның Сөннәт белән танышуына зур өлеш кертер, Аллаһы Тәгаләнең Расүленә булган мәхәббәтебезне ныгытыр, хәдисләрен һәм, гомумән, Сөннәтен өйрәнергә кызыксыну уятыр дип өметләнәбез.

Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм дистанцион рәвештә дә заказ бирергә мөмкин.

Интернет-кибет: **huzurshop.ru**
Кибет: Казан шәһ., Тукай ур., 36нчы йорт.
Тел.: +7 960 072-74-63.
Склад: Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт.
Тел.: +7 (966) 250-00-09.

# Инсафлы хатын-кызга яла ягу



Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

***«[Зинадан] Сакланган һәм [гаепләнгән нәрсәләрдән] хәбәрсез булган иманлы хатыннарга [зина кылу гаебе] ташлаган кешеләр [тәүбә итми торып] дөньяда һәм Ахирәттә ләгънәтләнгәннәр. Алар өчен бик каты газап бар».***

«Нур», 24:23

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җиде һәлакәткә китерә торган гөнаһтан сакланыгыз», – диде һәм алар арасында (зина турында уйлап та карамаган) инсафлы мөселман хатын-кызларына яла ягуны да искә алды.

Бер кеше Пәйгамбәребез янына килеп: «Мөселманнарның иң хәерлесе кем булыр», – дип сораган. «Кулыннан һәм теленнән калганнар имин булганы» (имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан: «Китаб-әл-Иман», 10. Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан: «Китаб-әл-Иман», 40), – дип әйтте.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

***«[Кылган бер гөнаһ сәбәпле] Казанган нәрсәләре булмыйча, иманлы ирләрне һәм иманлы хатыннарны рәнҗеткән кешеләр өсләренә бик әшәке эш һәм ап-ачык гөнаһ йөклиләр».***

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:58

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Үз колын (әлбәттә, ул кол чыннан да зина кылмаучы булса гына) зина кылуда гаепләгән кешене Кыямәт көнендә җәзага тартачаклар» (имам Бохари һәм имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

# Ялган шаһитлык китерү

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

***«[Рахманның сайлап алынган коллары] Янә ялганга шаһит булмыйлар...»***

«Фуркан / Аеручы», 25:72

Ибне Хөзәймә һәм Ибне Хиббәннән болай дип тапшырыла:

«Ялган шаһитлык китерү Аллаһыга ширек китерү белән бер».

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

***«Шулай [бу әмерләрне тотыгыз]! Кем Аллаһы хөрмәтле кылган нәрсәләрне олыласа, менә бу аның өчен Раббысы хозурында хәерлерәк. [Харамлыклары] Сезгә бер-бер артлы укылып торганнардан [үләксә һәм бисмилләһсез суелган хайваннардан тыш, дөя, сыер, сарык һәм кәҗә кебек] терлекләр сезгә хәләл кылынды. Моннан соң [матди нәҗесләрдән сакланганыгыз кебек, рухи] нәҗес булган потлардан да сакланыгыз, ялган сүздән дә [һәм ялган шаһитлыктан да] качыгыз».***

«Хаҗ», 22:30

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә:

«Ялган ант китерүче өчен җәһәннәмгә керү тиеш булганчыга кадәр аның аяклары да урыныннан кузгалмас», – дип әйтелә (Хәким, Мөстәдрәк, Китаб Әл-Әхкәм, 4/98.

Имам Зәһәби бу хәдисне дә дөрес дип саный: «Аллаһы Тәгалә ялган шәһадәт бирүченең урынын җәһәннәм итеп билгеләгәнче, аякларын да урыныннан кузгалта алмас»).

Ялган шаһитлык бирүче кеше бер үк вакытта берничә башка гөнаһ та кыла:

1. Ялган һәм яла ягу.

***«Һичшиксез, Аллаһы чиктән ашкан һәм ялганчы булган кешене һидаять итми».***

«Мөэмин», 40:28

Хәдистә болай дип әйтелә:

«Мөселманнарда, ялган һәм хыянәттән тыш, холыкның теләсә нинди сыйфатлары булырга мөмкин».

2. Ялган шаһитлык кылу, кешенең мөлкәтен, намусын һәм җанын югалтуга китерә.

3. Кешегә зыян китерү, яла ягудан табыш алу, чөнки бу кеше үзенә тыелган (анык булмаган) милекнең хуҗасы булачак һәм шуның аркасында җәза итеп җәһәннәмдә газап алачак.

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр дә мин бер кешенең милкен икенчесенә тапшыру турында гадел булмаган карар чыгарсам, икенчесе ул малны алмасын, чөнки бу адым белән мин аңа уттан кием әзерләячәкмен» (имамнар Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

4. Аллаһы Тәгалә билгеләгән мөлкәтнең, канның һәм намусның кагылгысызлыгын һәм тыелуы турындагы нигезләмәләрне юкка чыгару. Бу уңайдан Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Теләсә кайсы мөселман кешесенең намусы, милке һәм каны башка мөселман кешесе өчен изге булып тора» (имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан: Китаб Әл-Әдәб», 665).

Шулай ук тагын бер хәдистә болай дип әйтелгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Иң авыр гөнаһларны сезгә әйтимме? Ул:

– купаллалык (ширек);
– ата-анага каршы килү, тыңламау;
– ялган шаһитлык китерү.

Сәхабәләр Аллаһы Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу сүзләрне бик күп кабатлаганга күрә: «Әгәр дә ул туктаса иде!» – дип әйтергә мәҗбүр булганнар (имам Бохари, имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан).

■ **Имам Әз-Зәһәбинең «Әл-Кәбаир»** китабыннан

### Хәдис

***«Кайда гына булсаң да, Аллаһыдан курык. Яман эш артыннан, аны сөртә торган хәерле гамәл башкар һәм кешеләргә карата мөнәсәбәттә күркәм әхлаклы бул» (имам Әт-Тирмизи).***

* * *

***«Әгәр кол бу дөньяда икенче бер колның кимчелекләрен яшерсә, Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә әлеге кешенең кимчелекләрен яшерер» (имам Әл-Мөслим).***

Татар имамыХабибрахман Шакир:

# *Пакыстанның булачак президентының меңләгән күлләр иленә эләгүе*

Хабибрахман Шакирның авыр тормыш юлы турындагы хикәяләүне дәвам итеп, без аның ул вакытта Британия империясе составына кергән Пешавардагы тормышына тукталдык. Пешаварда Хабибрахман Шакир танылган татар дин белгече Муса Бигиев белән таныша. Аларның аңа хәтле үк тә таныш булулары ихтимал. Муса Бигиев сәфәрдән Япониягә кайтканда Һиндстан аша Әфганстанга элэгергә тели, әмма 1939 елда Англиянең колониаль хөкүмәте аны кулга ала. Ул 1945 елга кадәр Пешаварда кулга алынган хәлдә кала.

1942 елда меңләгән күлләр иленең булачак имамы гаиләсе белән Бомбейга (хәзер Мумбаи дип билгеле) күченергә карар кыла. Монда ул үзенең дини һәм укытучылык эшчәнлеген дәвам иттерә. Бомбейда Хабибрахман Шакирның укучылары арасында Пакыстанның булачак президенты һәм премьер-министры Зөлфикәр Али Бхутто (1928–1979) да була. Финляндиядә булганда ук Хабибрахман Шакир гомер буе кызыксынып, үзенең элеккеге укучысының уңышларын күзәтеп бара.

1946 елда Бомбейга Муса Бигиев килә. Күп еллар Пешавар төрмәсендә булганнан соң аның сәламәтлеге какшаган була. Монда ул ике ай чамасы хастаханәдә дәвалана, берничә операция кичерә. Нәкъ менә шул вакытта Каһирәгә китәр алдыннан Муса Бигиев, үзенең якташы, татарлар арасындагы белемле галимгә, ихтыярсыз иммигрант булган Хабибрахман Шакиргa, Тампере шәһәрендә финлы татарларның имамы буларга тәкъдим итә.

Муса Бигиев һәрвакытта да Финляндия татар җәмәгатьчелеге белән тыгыз элемтәдә яши. Тампере шәһәре татарлары бай һәм көчле җәмәгатьчелек була һәм шул вакытта ук күпсанлы җәмәгатьчелектән аерым мөстәкыйль рәвештә эшчәнлек алып баралар. Бу җәмәгатьчелек күптәннән белемле имамга һәм укытучыга мохтаҗ була. Шуңа да Муса Бигиев аларга Хабибрахман Шакирны тәкъдим итә.

Шул рәвешле, алдагы санда билгеләп үткәнчә, 1933 елда «Яңа милли юл» журналының җиденче саны Х. Шакир өчен зур роль уйный, чөнки анда әлеге шәхеснең Пешавардагы авыр тормышы турында мәкалә басыла, ә журналның икенче битенә Финляндиядән булган балаларның укытучылары белән төшкән фотосурәтләре һәм милли курслар турындагы мәгълүмат куела. Әле беркем дә 14 елдан соң Хабибрахман Шакир һәм аның гаиләсе өчен Финляндия аларның икенче ватанына әйләнәчәген күз алдына да китерә алмаган.

Һәм 1947 елда Муса Бигиев киңәше белән ул Тампере шәһәренең фин татарлары җәмәгатьчелегенә имам сыйфатында чакырыла. Бу вакытка Х. Шакир Ислам дөньясында танылган һәм авторитетлы галим була. Татар теленнән тыш, ул төрек, гарәп, урду һәм фарсы телләрен дә белгән. Аның төп вазифалары: җомга һәм бәйрәм намазларын үткәрү, вәгазьләр сөйләү һәм балалар укыту эшләре булган.

Әмма, кызганычка, аның бик күп гыйлемнәре, мөселман җәмәгатьчелегенең көнкүреш тормышында кулланылмаган. Тампереда ул бөтендөнья ислам галимнәре белән аралашуын һәм язышуын дәвам иттергән. Әгәр дини мәсьәләләрдә авыр сораулар килеп туса, барысы да аңа мөрәҗәгать итә торган булган. Хабибрахман Шакирның кыйммәтле азсанлы китаплардан торган зур китапханәсе булган. Һәм ул кызыксынучы кешеләргә китапларны алып торырга рөхсәт биргән.


*1966 елда Хабибрахман Шакир Советлар Союзына килгәч. Ташкентта үзенең элеккеге дусты Зыяэтдин Бабахан белән.*

1949 елда Хабибрахман Шакир «Финляндия Ислам Мәҗәлләсе» (Финляндиянең Ислам җыентыгы) дип исемләнгән җыентыкны чыгару эшенә тотына. Алга таба ул «Ислам Мәҗәлләсе» дигән исем белән чыга. Хабибрахман Шакир аның саннары татар эмиграциясе яшәгән бөтен почмакларга: Төркия һәм Япониягә кадәр таралу өчен тырыша.

Сәмигулла Вафин (Samiulla Wafin) белән берлектә алар «Дин дәреслеге вә Ислам тарихчәсе» дип аталган китап бастыралар. Х. Шакир шулай ук шагыйребез Габдулла Тукайга багышланган китап та нәшер итә. Ул үзе дә шигърияттә сәләтле була һәм татар халык көйләрен ярата.

Кызганычка, китап белән килеп туган техник проблемалар иҗатта үзләренең идеяләрен тулысынча тормышка ашырырга бирми. 1966 елда ул Советлар Союзында була ала һәм Зыяэтдин Бабахан, Габдулла Исаев кебек танылган мөселман эшлеклеләре белән очраша.

Аның хатыны Бибирайханә шулай ук гыйлемле хатын-кыз булган һәм камил рәвештә гарәп телен белгән. Ул Тампере татар җәмәгатьчелеге өчен бик күп эшләгән. Замандашлары аның бик әйбәт, ачык кеше булганын ассызыклый. 1972 елда корольнең шәхси чакыруы белән, Хабибрахман Шакир хәләл җефете белән бергәлектә, Согуд Гарәбстанына бара һәм Мәккәдә хаҗ кыла. Сәфәр вакытында Х. Шакир король Фейсал бине Габделгазиз Әл-Согуд (идарә итү еллары 1964-1975) белән шәхсән таныша.

1974 елда галимнең хәләл җефете Бибирайханә үлә, ә бер елдан соң 1975 елда Хабибрахман Шакир үзе дә бакыйлыкка күчә. Аларны Хельсинкиның мөселман татар зиратында җирлиләр.

Күрүебезчә, Хабибрахман Шакирның тормышы бик авыр һәм үзенчәлекле булган. Меңләгән күлләр иленә элэгер өчен аңа күп авырлыклар һәм югалтулар кичерергә туры килгән. Бу татар халкының дини һәм милли эшлеклесе булган шәхес тормышының бер өлешен генә сурәтләү иде һәм ул бүгенге заман тикшерүчеләренең дә аерым игътибарын таләп итә.



*Хабибрахман Шакир һәм хатыны Бибирайханәнең каберләре (шәхси архивтан).*

■ **Мөхсин НУРУЛЛА** язмасы,
**islam-today.ru** сайтыннан тәрҗемә

# Игелек кылуның ләззәте

*Башкаларга игелек кылуның тәмен, ләззәтен, ихластан кешеләргә ярдәм итеп яшәүчеләр генә тоя*

Берьюлы укытучыбыз: «Кешегә авыр булганда янына килеп юатып була, әмма аның шатлыклы, бәхетле чагында килеп, куанычын уртаклашу авыр», – дигән иде. Без 18-19 яшьлек студентлар бу сүзләрнең мәгънәсен тулысынча аңлап бетермәдек.

Әйе, кешеләр һәрдаим аралашып, еш кына тормышларында булган вакыйгалары белән уртаклашып яши. Һәр кешенең тормышында уңышлар да, күңелсезлекләр дә була. Кеше төшенкелеккә бирелергә дә, килеп туган проблемалары сәбәпле, боегып йөрергә дә мөмкин. Әлбәттә, без һәр очракта да ярдәм итә алмыйбыз. Әмма мөселман кешесенең үз кардәшләре алдында хаклары бар. Һәм аларны үтәгән очракта без азмы-күпме дәрәҗәдә ярдәм иткән булабыз.

***Беренчесе, ихластан сәламләү.***

Чыннан да, сәлам бирү бик тә мөһим күрсәткеч. Кешенең елмаеп, ачык йөз белән сәлам бирүе аның хакындагы беренче фикерне тудыра. Кайбер кеше нинди борчулы вакытында да кешеләргә ачык йөз күрсәтә, матур итеп исәнләшә ала. Бу, әлбәттә, аның күңел байлыгыннан килә. Расүлебез бер хәдисендә: «Кардәшеңә карата йөзеңдәге елмаюың – синең өчен садака», – дигән (имам Әт-Тирмизи).

Әбү Зәрр радыяллаһу ганһе болай дип риваять иткән: «Берьюлы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм миңа: «Беркайчан да шәригать буенча макътала торган нәрсәләргә салкын карама, хәтта кардәшеңне ачык йөз белән каршы алу тиешле булуда да», – дип әйтте (имам Әл-Мөслим, Ибне Хиббән).

Димәк, кардәшебез белән очрашканда ачык йөз белән исәнләшүебез – аңа карата булган беренчел мөнәсәбәтебезне һәм үзебезнең әхлак дәрәҗәсен күрсәтә. Бәлки нәкъ менә хәзер ул безнең елмаеп сәлам бирүебезгә мохтаҗдыр. Ә без, үз чиратыбызда, чиксез әҗер-савапларга ирешкән булабыз. Боларга җитди карасак иде.

***Икенчесе, ярдәм һәм кайгырту.***

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мөселман кешесенә кайгы килгәндә ярдәм иткән кешене Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә үзен кайгыдан имин кылыр», – дигән (имам Мөслим). Икенче бер хәдистә: «Аллаһы Үзенең колына, ул үзенең кардәшенә ярдәм иткәнгә кадәр булышачак», – дип әйтелгән (имам Мөслим).

Димәк, без кардәшебезгә ярдәм итеп, үзебез дә Аллаһының рәхмәтенә ирешәбез. Бирелә халкыбызның: «Бер рәхмәт мең бәладән коткара», – дигән мәкале исебезгә төшә. Моннан тыш, кемгәдер ярдәм итеп, без үзебезне бәхетле һәм канәгать итеп тоябыз. Башкаларга игелек кылуның тәмен, ләззәтен, ихластан кешеләргә ярдәм итеп яшәүчеләр генә тоя, дип әйтүләре шушыдыр.

***Өченчесе, хәерле сүз.***

Халкыбыз: «Кеше сүзе кеше үтерә», – дигән. Кайвакытта безнең бер сүзебез кеше өчен шулхәтле мөһим булырга, хәтта ул кешенең соңгы өметен уятып, яшәргә көч бирергә сәләтле була ала. Кайчакларда урынсыз әйтелгән сүз, кешегә тагын да ныграк авырлык китерергә мөмкин.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хәерле сүз – садака», – дигән (имам Әл-Мөслим, имам Әл-Бохари). Икенче бер хәдисендә: «Ярты хөрмә җимеше белән булса да, үзегезне Уттан саклагыз. Моны да таба алмасагыз, хәерле сүз белән ярдәм итегез», – дигән (имам Әл-Бохари, имам Әл-Мөслим).

Боларны үтәү кыен түгел, моның өчен акча да, әллә ни зур тырышлык та таләп ителми. Әмма Аллаһыдан бирелә торган әҗер-савап һәм бу кешенең рәхмәт сүзләре ике дөнья бәхетебезгә сәбәпче булачак. Җитмәсә, кешеләргә яхшылык кылуыбыз күңел халәтебезгә дә тәэсир ясый. Бу халәтне бары ихлас йөрәктән һәрдаим игелек кылучылар гына тоя ала.

■ **Айсылу ЮЛДАШЕВА**

## Кыямәт көненең дәвамлыгы

Бер тәкъва кеше һәр төнен гыйбадәт кылуга һәм тулы Коръәнне укуга багышларга тырышкан. Берьюлы аңа кешеләр:

– Син үзеңне ардырасың. Ял өчен бераз вакыт тап, – дип әйткәннәр.

Тәкъва иясе болай дип сораган:

– Бу дөньяның барлыкка килүенә ничә ел?

– Җиде мең ел.

– Кыямәт көненең дәвамлыгы ничә ел?

– Илле мең ел.

– Кеше бу дөньяда җиде мең ел яшәсә дә, Кыямәтнең бер көне өчен, шушы җиде мең елны гыйбадәттә үткәрү хәерлерәк. Кешегә илле мең ел дәвам иткән Кыямәт көне авырлыкларына түзүгә караганда, әлеге җиде мең елны гыйбадәттә үткәрү җиңелрәк булыр иде.

**Нәсыйхәт:**

**«Хәлбуки, дөнья тормышы – [ләззәтләре белән] байлыгы Ахирәт янында [һич чагыштырып булмаслык] бик аз нәрсә».**

«Әт-Тәүбә», 9:38

## Көне-төне гыйбадәт кылу өчен бүләкләү

Бер яшь кеше үзен тулысынча көне-төне гыйбадәт кылуга тапшырган. Танышлары аңа: «Нигә син үзеңне ардырасың? Сиңа ял кирәк», – дип әйткәннәр. Яшь егет:

– Берьюлы мин төшемдә җәннәттәге алтын һәм көмеш кирпечләрдән төзелгән сарай күрдем. Аның балконнары да алтын һәм көмештән иде. Ике балкон арасында (ягъни һәрбер бүлмәдә) хур кызлары бар. Алар моңа кадәр берәү дә күрмәгән матурлыкка ия иде. Маңгай чәчләре иңбашларына кадәр төшеп тора. Шуларның берсе миңа елмайганда тешләренең ялтыравы җәннәтне яктыртты. Бу хур кызы елмаеп болай дип әйтте: «Әгәр минем белән булырга, минем синеке, синең минеке булуыбызны теләсәң, Аллаһыга көнен һәм төнен гыйбадәт кыл», – дип әйтте. Шуннан соң мин йокымнан уяндым. Һәм көнен-төнен гыйбадәт кылу минем тәкъдиремә әйләнде, – дип сөйләгән.

**Нәсыйхәт:**

Һәрбер бәхетнең авырлыгы бар. Бу – дөнья һәм Ахирәт тормышына да кагыла. Иң кыйммәтле казылмалар җирнең иң тирән урыннарыннан табыла һәм кулланылышка керер алдыннан бик күп этаплар үтә. Шуның өчен нигъмәтләр белән тулы җәннәткә ия булыр өчен бу кыска гомерне гыйбадәттә һәм изге гамәлләр кылуда үткәрергә кирәк.

## Кабер – яхшы йә яман гамәлләр сандыгы

Әбү Мөсәйра рахимәһуллаһи болай дип сөйләгән: «Кабергә иңдергәннән соң бер кешегә Мөнкир вә Нәкир исемле фәрештәләр килгән. Кулларында чыбыркы булган бу затлар: «Без сиңа йөз тапкыр сугачакбыз», – дип әйткәннәр».

Бу кеше: «Зинһар мине кыйнамагыз, мин үз гомеремдә изге гамәлләр кылган идем», – дип әйтә. Бу сүзләрне ишеткән фәрештәләр сугуның саннарын кимәтә. Кеше изге гамәлләрен санауны дәвам иттерә. Ахыр чиктә фәрештәләр бер тапкыр сугуны гына калдыра. Һәм: «Без сиңа бер тапкыр чыбыркы белән сугачакбыз. Аннан котыла алмыйсың», – диләр. Алар аңа сукканнан соң кабер ут белән тула.

Бу кеше фәрештәләрдән: «Нәрсә өчен суктыгыз миңа?» – дип сорый. Фәрештәләр: «Берьюлы син ярдәм сорап утыручы бер мохтаҗ кеше яныннан ярдәм күрсәтмичә узып киттең», – дип әйтә.

**Нәсыйхәт:**

Мөнкир вә Нәкир – кабердә сорау алучы фәрештәләр. Алар бу исемнәренә кешеләр беркайчан да күрмәгән кыяфәттә килгәннәре өчен ия булганнар. Мөэмин кеше һичшиксез яхшы гамәлләренең дә, начарларының да нәтиҗәсен күрәчәк. Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә иң Гадел Зат.

**«Рухуль Бәйан»** китабыннан

# Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе




## Тууы

Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе якынча 593 елда Мәккә шәһәрендә, хәниф Зәед бине Гамр бине Нөфәйл һәм Фатыйма бинте Нәҗәт гаиләсендә дөньяга килгән. Җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең берсе.

## Нәселе

Сәгыйд бине Зәеднең әтисе – Зәед бине Гамр бине Нөфәйл күпаллалыкны – акылга каршы килү, ә потларга табынуны – мәгънәсезлек дип санаган. Ул бераллалыкка ышанып, Ибраһим галәйһиссәлам динендә булган. Үз тарафдарларын эзләп, Шам җиренә барып җиткән һәм бер рухани (раһиб) аңа болай дип әйткән:

– Мәккә җиренә кайт. Синең халкың арасында Ибраһим галәйһиссәлам динен яңартучы булыр.

Шулвакытта Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне хак юлны күрсәтүче расүл итеп җибәрә.

Зәед бине Гамр Мәккәгә кайтканда бәдәви гарәпләр (кайбер чыганакларда насаралар дип әйтелә) тарафыннан үтерелә. Үлгәндә болай дип дога кылган: «Йә Раббым, мине шул нигъмәттән мәхрүм кылсаң, минем улым Сәгыйдне мәхрүм кылма!»

Аллаһы Тәгалә Зәед бине Гамрның догасын кабул кылган.

## Ислам динен кабул итүе

Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе иң беренчеләрдән булып ислам динен кабул иткән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнар белән Әркамә йортында очраша башлаганчы ук инде диндә булган, ул чагында аңа 20 яшь тирәсе булган.

## Гаилә хәле

Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһенең Фатыйма исемле сеңлесенә өйләнгән һәм Гомәр радыяллаһу ганһенең иман китерүенә сәбәпче булган.

Белүебезчә, Гомәр радыяллаһу ганһе җаһилият вакытында ислам диненең дошманы булган. Ислам динен кабул итүчеләрне газаплап, мөселманнарга аңардан бик зур зарар ирешкән.

Бервакыт ул хәтта пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмне, гарәпләрне ата-бабалар диненнән читләштереп, ислам диненә чакырганы өчен үтерергә теләгән. Барыр юлында апасы Фатыйма һәм аның ире Сәгыйд бине Зәеднең ислам динен кабул иткәннәрен белгән.

Гомәр радыяллаһу ганһе иң элек апасы Фатыйма йортына керергә карар кылган. Бу вакытта Фатыйма ире Сәгыйд белән Хәббән бине Мунзирдән Коръән аятьләре өйрәнеп утыра торган булганнар. Ачулы Гомәрнең килеп ишек кагуыннан алар куркып калганнар. Ишекне ачмауларын күргәч, Гомәр радыяллаһу ганһе өйгә бәреп үк кергән. Кергән чакта: «Мин сезнең ислам динен кабул иткәнегезне ишеттем», – дип Сәгыйд бине Зәедне сугып еккан. Ирен якларга теләгән апасына да өлеш чыгарган.

Егылган Фатыйманы һәм Сәгыйдне күреп, ул уйга калган: «Бу кешеләрне күрче, диннәре өчен ничек нык торалар. Безнең арабызда потлар өчен бер тамчы кан түккән кеше дә юк». Ул кылган гамәлләре өчен бик нык үкенгән һәм апасыннан: «Сез нәрсә укыдыгыз? Бир әле, мин дә укып карыйм», – дип сораган. Фатыйма аңа: «Юк, бу – Коръән. Аңа чиста килеш кенә тотыналар», – дип әйткәч, Гомәр радыяллаһу ганһе гөсел алып кергән.

Шуннан соң апасы кулындагы төргәкне аңа биргән һәм ул андагы «Та Һа» сүрәсен укыган. Шулчак ул: «Бу нинди гаҗәеп, матур сүзләр. Кешеләр бу сүзләрне әйткән кешедән кала беркемгә дә гыйбадәт кылырга тиеш түгелләр! Мине Мөхәммәд янына алып барыгыз!» – дип әйткән.

Гомәр радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм йортына барып, аның каршысына килеп шәһадәт кәлимәсен әйткән. Шул рәвешле Ислам динен кабул иткән. Күргәнебезчә, Гомәр радыяллаһу ганһенең ислам динен кабул итүендә Сәгыйд бине Зәеднең дә өлеше булган.

## Сыйфатлары

Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе ачык йөрәкле, пакь җанлы, йомшак күңелле, тәкъва һәм дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичкән, халык арасында хөрмәт ителә торган зат булган.

Сәхабә буларак, Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе күп вакытын пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында үткәрергә тырышкан. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ярдәм итүчеләрдән булып, һәрбер сугышта катнашкан. Ул бары тик Бәдер сугышында гына катнаша алмаган, чөнки ул вакытта Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вазифаларын башкарырга дип Мәдинәгә киткән булган.

Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе киң күңелле булуы белән аерылып торган. Ярдәм сорап аңа мөрәҗәгать итсәләр, ул беркайчан да каршы килмәгән. Ганимәт малыннан үзенә тиешле булган өлешне дә фәкыйрь мөселманнарга тарата торган булган, күп очракта үзе ач калган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң да Сәгыйд бине Зәед мөселманнар өчен зур тырышлыклар куйган. Ярмук сугышында мөселманнар Аллаһы Тәгаләнең ярдәменә ышанып, иманнарында нык торып, дошманнарны җиңгәннәр. Шул вакыттан соң Шам җирләре бер-бер артлы мөселманнар идарәсенә күчеп барган.

Бу вакыйгалардан соң, Әбү Гобәйдә бине Җәррах Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһене Димәшкъ җитәкчесе итеп билгеләп куйган. Ләкин Сәгыйд бине Зәед бу хакта белгәч, әлеге вазифадан баш тарткан, чөнки аңа дөнья өстенлекләре түгел, ә Ахирәт әҗерләре якынрак булган.

Сәхабәләр төрле авырлыкларга очраган кебек, Сәгыйд бине Зәедкә дә төрле сынаулар аша үтәргә туры килгән.

Риваятьләрдә аның белән булган бер вакыйгага килә. Мәдинә җирендә Әрва бинте Убәйсә исемле хатын үзенең җир өлешен алган дип Сәгыйд бине Зәедне гаепләгән һәм хәлифә Мәрван бине Хәкәмгә шикаять кылган. Мәрван бине Хәкәм бу хәлгә ачыклык кертер өчен, Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе янына үз кешеләрен юллаган. Сәгыйд бине Зәед аларга болай дип җавап биргән: «Әллә сез мине гаделсезлектә гаеплисезме? Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәү хаксыз кеше җиреннән бер карыш өлеш алса, Кыямәт көнендә ул җир аның муенына уралыр», – дип әйтте».

Риваятьләрдә Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһенең хаклыгы расланганы турында әйтелә.

## Вафаты

Сәгыйд бине Зәед радыяллаһу ганһе 51 нче һиҗри елда Мәдинә шәһәре янындагы Акыйк җирлегендә вафат булган. Аның җәсәден Мәдинәгә алып килеп дәфен кылганнар. Аны озатучылар арасында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күренекле сәхабәләре Сәгъд бине Әби Вәккас, Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһүмәләр булган.

■ Сәхифәне
**Лилия ХӘЛӘФЕТДИНОВА**
әзерләде

# Кайнар диңгез юлы



*(Повестьтән өзек)*

*(Дәвамы. Башы алдагы саннарда)*

## Салкын җил җылысы

Сургутның киң урамы буйлап Ханты-Манси округы мөфтие Таһир хәзрәт Саматов белән Рәйсә абыстай җәяүләп мәчеткә якынлашып килә. Себернең әче җиле колак яфракларын чеметә. Тик, алар аны сизмиләр. Егерме алты ел дәвамында салкын җилгә каршы көрәшеп, аларның тәннәре генә түгел, рухлары да чыныкты.

– Рәйсә, сизәсеңме, мәчет бинасыннан тирә-якка сирпелгән якты нур, әйтерсең лә, салкын җилне җылыта. Бу мәһабәт мәчетне Сургутка килеп яши башлаган вакытларда ук төшләремдә күреп саташтым. Йә Раббым, Сиңа нинди генә рәхмәтләр әйтсәк тә аз. Себер җирендә яшәүче мөселманнарны дингә тарту җиңел булмады, авыр юллар аша ирешелде, Аллаһ һәр эшебезне җиңеләйтергә ярдәм итте...

– Монда килгәч, узган юлыбызга әйләнеп карагач, үзебездәге ихтыяр көченә шаккатам. Хезмәт хакы да түләнмәде бит әле. Ашарга алырга акчабыз булмаган көннәребез дә байтак булды. Хәтереңдәме, Камилнең: «Бүген уразага гына керәсем калган икән», – дигән сүзе? Таһир хәзрәт башын кагып куйды. – Улымның шул сүзе йөрәгемә кадалып калды. Аллага шөкер, тамаклары туеп кайта дип, мәҗлесләргә балалар белән барганга куана идем. Нинди көннәребез бар иде, хәзрәт. Казыксыз җирдә казык кагудан башланган тормыш юлы буйлап атлый-атлый, пенсия яшенә килеп җиттек бит.

– Минем күңелдә Әлфинурның сүзе калды. Гает көнне барыбызны да Галия апа мәҗлескә чакырды. Шуннан кайткач: «Бүген безгә дүрт сөлге, дүрт эскәтер бирделәр», – дип куанып, әнигә шалтыратып әйткәнен хәтерлим. – Аннары судья Гарифҗан абыйның хатыны Фәния апа да авыр вакытта бик ярдәм итте безгә. Хәтереңдәме, бер тартма сгущенка китергәне?

– Яхшылык онытыламы соң? Барысын да хәтерлим... Таһир хәзрәт адымын әкренәйтте.

– Соңгы вакытта монда үткән гомер юлыбыз турында еш уйлыйм. Безгә күрсәткән ярдәме өчен Аллаһка рәхмәт укыйм. Күңелләренә Аллаһ иман иңдергән җитәкчеләребез белән бергәләп Себер җирендә нинди зур эшләр башкарылды! 1995 елдан башлап, Ханты-Манси округы буенча Когалым, Нефтюганск, Федоровка бистәсендә, Нижневартовск, Лангипаст шәһәрләрендә нинди зур мәчетләр салынды!

– Ул елларда син айга ничә көн өйдә кундың икән? Мәчетләрнең документлары буенча айга ничә тапкыр Уфага барганыңны хәтерлисеңме? Ул шәһәрләрдә мәхәллә төзегән вакытларыңны исеңә төшергәнең бармы? Имамнар куя башлагач, нинди ызгышлар аша уздың? Дипломант акылы белән идарә итә алганың өчен генә барысын да җайга сала алдың, хәзрәт.

– Күпмилләтле халык яши торган шәһәрләрдә дини вәзгыять катлаулы юллар аша хәл ителде. Чәчән белән дагыстан халкы имам итеп үз кешесен куярга омтылды. Ул елларда милли политиканы дөрес юлдан алып бару иң җитди бурыч булды. Мәчетләргә чит республикадан килгән халыкларның хуҗа булырга тырышуы җирле халык белән ике арада киеренкелек барлыкка китерде. Безнең диндә имамнарның халык тарафыннан сайланып куелу тәртибе юклыгын аңларга теләмәделәр. Имамнар мөфти тарафыннан шәһадәтнамә белән билгеләнеп куелганын аңнарына сеңдергәнче күпме көч куелды. Әгәр дә халык тарафыннан сайланып куела торган булсамы, хәтта күз алдына китерүе дә куркыныч, һәр милләт үзенекен сайлар да, ызгыш-талаш, фетнә барлыкка килер иде. Исеңдәме, Когалым шәһәрендә имам итеп Хәйдәр хәзрәтне куйдык кына, икенче көнне кыйнап киттеләр. Без сайлап куйган имамнарга буйсынмаска тырыштылар. Бездә бер генә төрле – Әбү Хәнифә мәзһәбе икәнлеген аңлату өчен мәчетләрдә кунарга калган вакытларымны искә төшерсәм, хәзер дә тәнем чемерди башлый. Аллага шөкер, барысы да ипләп кенә җайлашып китте. Имамнарга һаман да күп милләтле халык белән уртак дипломатия саклау сәясәтен аңлатуны туктатырга ярамый.

Рәйсә абыстай ул еллардагы авырлыкларны күз алдыннан үткәрде. Ханты-Манси шәһәренә паром белән барган вакытларын исенә төшерде. Хатынының уйларын укыгандай:

– Хәйдәр хәзрәт каршылыкларга нык торды ул. Шул чорда чалланып калганга, шул округның мөфтие итеп билгеләнде дә инде ул, – диде Таһир хәзрәт. Бераз сүзсез барды: – Булдыра алганның барысын да үз вакытында эшләдек. Ерак Көнчыгыш Сахалин, Владивосток, Благовещенск, Чита, Иркутск шәһәрләрендә дә мәхәллә төзеп, мәчетләр торгызылды. Үзләре ярдәм сорап, миңа хат яздылар. Сургут мәчете манарасыннан сирпелгән изге нур яктысы, аларның иманнарын уятты.

Абыстайның уйлары янә үткәннәргә барып тоташты. Иренең Себер һәм Ерак Көнчыгыш мөфтие итеп билгеләнгәч, баш-аягы белән эшкә чумган елларны күз алдына китерде. Мәчетләр салу өчен җирләр алып йөргәндә, атналар буе өйгә кайтып кына алмады. Телефон аша гына хәл белешеп тордылар. Сахалинга самолет белән унбер сәгать очарга кирәк. Кемерово һәм Иркутск шәһәрләрендә мәчетләр тапшырылгач, Таһир хәзрәт аның кулына «Халыклар дуслыгы» медале алып кайтып тоттырды.

– Үз бурычыбызны намус белән үтәгән өчен бирелде бу медаль, абыстаем, икебезгә дә дип кабул итик, – диде.

Рәйсә абыстай шул чакларны исенә төшереп, үз алдына елмаеп куйды. Дөньяда кешене изге гамәлләре йөртә шул. Таһире дә һәрдаим: «Кемгә нинди яхшылык эшләргә мөмкинлегебез бар, барысын да булдырырга тырышыйк», – дип әйтеп тора. Мәчеткә йөреп белем алган кешеләрне ике тапкыр ташламалы бәягә Хаҗга алып бардылар. Рәйсә абыстай Хаҗ гамәлен башкарганда, үзләренә һәм балаларына уңышлы тормыш сорады. Аллаһ ананың кулын күтәреп сораган үтенечен ишетте. Уллары Камил Мәскәү университетында чит телләр факультетында укыды. Әлфинур укытучы һөнәрен сайлады. Кызларының тормышы үзләре кебек динне үстерүгә хезмәт итүче Самара егете белән бәйләнде. Камил Сургут мәчетенең имамы итеп билгеләнде. Килене Гөлназ да үзенә охшап килде. Ачык йөзе, ипле холкы, тыйнаклыгы өчен ярата ул аны. Буйга җитеп үсеп килүче өч оныгына карый да, үзенең гомер көзенә кереп барганын аңлый. Сургут шәһәрендә туган кызлары Сара, югары белем алыр өчен, туган ягына – Казанга кайтты. Кызын сагыну сызлавы белән, ул хәзер туган ягына ешрак кайта. Төпчек кызлары аларны туган якларына якынайтты. Үз уйларына уралып, мәчет комплексына килеп җиттеләр.

– Карале, әтисе, нинди матур безнең мәчетебез! Тирә-якка нур сибә! – диде абыстай, ихласлык белән куанып.

– Гомер юлыбыз, тормышыбыз Себер җирендә Аллаһ йортлары, мәдрәсәләр салу өчен багышланды, кадерле абыстаем. Мәчеттән сирпелгән иман нуры кешеләрнең күңеленә изгелек балкышы сала. Ә изге кеше – мәчетне урап уза алмый. Күрәсеңме, җомга намазына мөселман туганнарыбыз ташкын кебек агылып килә. Кайчандыр, олы хыял гына булса, бүген чынбарлык!

Таһир хәзрәт белән абыстай мәчет ишегә янына якынлашкач, төрле яктан сәламләп, аларга юл бирделәр.

■ **Гөлсинә ГАЛИМУЛЛИНА**

*(Дәвамы киләсе санда)*

**ДҮШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ**

07:00 «Хәерле сәгатьтә»
08:00 «Намазга өйрәник»
08:20 «Татарлар тарихы»
09:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:20 «Бер мәчет тарихы»
09:30 «Һөнәрләр»
09:45 «Таз малай» мультфильмы
10:00 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
10:10 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
10:35 «Җан авазы»
10:40 «Тәмле булсын»
11:00 «Хәзинә»
11:20 «Иң гүзәл исемнәр»
11:30 Онлайн-мәдрәсә
12:00 Азан
12:05 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
12:25 «Разговоры о важном»
12:35«Счастье без границ»
12:45 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
12:55«Малец удалец» мультфильм
13:10 «Золотой век исламской цивилизации»
13:20 «Голос разума»
13:50 «Готовимся к Рамадану»
14:00 «Продуктивный Рамадан»
14:10«Хузур-вояж» с Антоном Кротовым
14:30 Фәнни-танып белү фильмы
15:00 «Халид бин Валид» нәфис фильмы
16:00 «Хәерле сәгатьтә»
17:00 «Намазга өйрәник»
17:20 «Татарлар тарихы»
18:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:20 «Бер мәчет тарихы»
18:30 «Һөнәрләр»
18:45 «Таз малай» мультфильмы
19:00 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
19:10 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
19:35 «Җан авазы»
19:40 «Тәмле булсын»
20:00 «Хәзинә»
20:20 «Иң гүзәл исемнәр»
20:30 Онлайн-мәдрәсә
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Шекер ходжа» мультфильм
21:20 «Малец удалец» мультфильм
21:35 «Голос разума»
22:05 «Золотой век исламской цивилизации»
22:15 «Разговоры о важном»
22:25 «Счастье без границ»
22:35 «Готовимся к Рамадану»
22:45 «Продуктивный Рамадан»
22:55 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
23:15 «Хузур-вояж» с Антоном Кротовым
23:25 Фәнни-танып белү фильмы
23:55 «Халид бин Валид» нәфис фильмы
01:05 Коръәни Кәрим укылышы

**СИШӘМБЕ**

07:00 «Хәерле сәгатьтә»
08:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
08:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин
08:45 «Иң гүзәл исемнәр»
08:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:05 «Тәмле булсын»
09:25 «Намазга өйрәник»
09:45 «Гаилә дәресләре»
10:15 «Хикмәтле хикәяләр»
10:25 «Таз малай» мультфильмы
10:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
10:50 «Бер хәдис – бер җавап»
11:00 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
11:25 «Җан авазы»
11:30 Онлайн-мәдрәсә
12:00 Азан
12:05 Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)
12:30 «Продуктивный Рамадан»
12:40 «Маленькие взрослые»
12:45 «Шекер ходжа» мультфильм
12:55 «Малец удалец» мультфильм
13:10 «Исламские финансы»
13:30 «Момент истины» Гали Абдусалимов белән
13:45 «Золотой век исламской цивилизации»
13:55 «Счастье без границ»
14:05 «Такой татарский русский»
14:10 «Учимся совершать намаз» (хатын-кызлар өчен)
14:30 Фәнни-танып белү фильмы
15:00 «Халид бин Валид» нәфис фильмы
16:00 «Хәерле сәгатьтә»
17:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
17:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин
17:45 «Иң гүзәл исемнәр»
17:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:05 «Тәмле булсын»
18:25 «Намазга өйрәник»
18:45 «Гаилә дәресләре»
19:15 «Хикмәтле хикәяләр»
19:25 «Таз малай» мультфильмы
19:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
19:50 «Бер хәдис – бер җавап»
20:00 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
20:25 «Җан авазы»
20:30 Онлайн-мәдрәсә
21:00 «Шекер ходжа» мультфильм
21:10 «Малец удалец» мультфильм
21:25 «Счастье без границ»
21:35 «Исламские финансы»
22:00 Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)
22:25 «Готовимся к Рамадану»
22:35 «Такой татарский русский»
22:40 «Учимся совершать намаз» (хатын-кызлар өчен)
23:00 «Есть вопрос – есть хадис»
23:20 «Золотой век исламской цивилизации»
23:30 Фәнни-танып белү фильмы
00:00 «Халид бин Валид» нәфис фильмы
01:00 Коръәни Кәрим укылышы

**ПӘНҖЕШӘМБЕ**

07:00 «Хәерле сәгатьтә»
08:00 Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
08:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин
08:45 «Иң гүзәл исемнәр»
08:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:05 «Тәмле булсын»
09:25 «Намазга өйрәник»
09:45 «Гаилә дәресләре»
10:15 «Хикмәтле хикәяләр»
10:25 «Таз малай» мультфильмы
10:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
10:50 «Бер хәдис – бер җавап»
11:00 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
11:25 «Җан авазы»
11:30 Онлайн-мәдрәсә
12:00 Азан
12:05 Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)
12:30 «Готовимся к Рамадану»
12:40 «Такой татарский русский»
12:45 «Шекер ходжа» мультфильм
12:55 «Малец удалец» мультфильм
13:10 «Халяль-лайфстайл»
13:30 «Счастье без границ»
13:40 «Минбар истории»
14:10 «Учимся совершать намаз» (хатын-кызлар өчен)
14:30 Фәнни-танып белү фильмы
15:00 «Халид бин Валид» нәфис фильмы
16:00 «Хәерле сәгатьтә»
17:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
17:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин
17:45 «Иң гүзәл исемнәр»
17:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:05 «Тәмле булсын»
18:25 «Намазга өйрәник»
18:45 «Гаилә дәресләре»
19:15 «Хикмәтле хикәяләр»
19:25 «Таз малай» мультфильмы
19:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
19:50 «Бер хәдис – бер җавап»
20:00 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
20:25 «Җан авазы»
20:30 Онлайн-мәдрәсә
21:00 «Шекер ходжа» мультфильм
21:10 «Малец удалец» мультфильм
21:25 «Минбар истории»
21:55 «Халяль-лайфстайл»
22:15 «Счастье без границ»
22:25 Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)
22:50 «Учимся совершать намаз» (хатын-кызлар өчен)
23:10 «Готовимся к Рамадану»
23:20 «Продуктивный Рамадан»
23:30 Фәнни-танып белү фильмы
00:00 «Халид бин Валид» нәфис фильмы
01:00 «Такой татарский русский»
01:05 Коръәни Кәрим укылышы

**ҖОМГА, ЯКШӘМБЕ**

07:00 «Хәерле сәгатьтә»
08:00 «Хәзинә»
08:20 «Татарлар тарихы»
09:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:20 «Бер мәчет тарихы»
09:30 «Һөнәрләр»
09:45 «Таз малай» мультфильмы
10:00 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
10:10 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
10:35 «Җан авазы»
10:40 «Тәмле булсын»
11:00 Онлайн-мәдрәсә
11:30 «Минбар»
12:00 Азан
12:05 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
12:25 «Разговоры о важном»
12:35 «Счастье без границ»
12:45 «Шекер ходжа» мультфильм
12:55«Малец удалец» мультфильм
13:10 «Золотой век исламской цивилизации»
13:20 «Голос разума»
13:50 «Готовимся к Рамадану»
14:00 «Продуктивный Рамадан»
14:10 «Хузур-вояж» с Антоном Кротовым
14:30 Фәнни-танып белү фильмы
15:00 «Благочестивая Марьям» нәфис фильм
16:00 «Хәерле сәгатьтә»
17:00 «Хәзинә»
17:20 «Татарлар тарихы»
18:10 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:20 «Бер мәчет тарихы»
18:30 «Һөнәрләр»
18:45 «Таз малай» мультфильмы
19:00 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
19:10 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
19:35 «Җан авазы»
19:40 «Тәмле булсын»
20:00 Онлайн-мәдрәсә
20:30 «Минбар»
21:00 «Сказки снов» – нәниләр өчен программа
21:10 «Шекер ходжа» мультфильм
21:20 «Малец удалец» мультфильм
21:35 «Голос разума»
22:05 «Золотой век исламской цивилизации»
22:15 «Разговоры о важном»
22:25 «Счастье без границ»
22:35 «Готовимся к Рамадану»
22:45 «Продуктивный Рамадан»
22:55 «Учимся совершать намаз» (ир-атлар өчен)
23:15 «Хузур-вояж» с Антоном Кротовым
23:25 Фәнни-танып белү фильмы
23:55 «Благочестивая Марьям» нәфис фильмы
01:05 Коръәни Кәрим укылышы

**ШИМБӘ**

07:00 «Хәерле сәгатьтә»
08:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
08:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин
08:45 «Иң гүзәл исемнәр»
08:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
09:05 «Тәмле булсын»
09:25 «Намазга өйрәник»
09:45 «Гаилә дәресләре»
10:15 «Хикмәтле хикәяләр»
10:25 «Таз малай» мультфильмы
10:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
10:50 «Бер хәдис – бер җавап»
11:00 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
11:25 «Җан авазы»
11:30 Онлайн-мәдрәсә
12:00Азан
12:05 Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)
12:30 «Готовимся к Рамадану»
12:40 «Такой татарский русский»
12:45 «Шекер ходжа» мультфильм
12:55 «Малец удалец» мультфильм
13:10 «Халяль-лайфстайл»
13:30 «Счастье без границ»
13:40 «Минбар истории»
14:10 «Учимся совершать намаз» (хатын-кызлар өчен)
14:30 Фәнни-танып белү фильмы
15:00 «Благочестивая Марьям» нәфис фильмы
16:00 «Хәерле сәгатьтә»
17:00 «Тәфсир дәресләре. Тимергали Юлдашев»
17:30 «Нуруль-Идах». Рөстәм Вәлиуллин
17:45 «Иң гүзәл исемнәр»
17:55 «Сүз эчендә хикмәт бар»
18:05 «Тәмле булсын»
18:25 «Намазга өйрәник»
18:45 «Гаилә дәресләре»
19:15 «Хикмәтле хикәяләр»
19:25 «Таз малай» мультфильмы
19:40 «Шөкер хуҗа» мультфильмы
19:50 «Бер хәдис – бер җавап»
20:00 «Мәслихәт» Илфар хәзрәт белән
20:25 «Җан авазы»
20:30 Онлайн-мәдрәсә
21:00 «Шекер ходжа» мультфильм
21:10 «Малец удалец» мультфильм
21:25 «Минбар истории»
21:55 «Халяль-лайфстайл»
22:15 «Счастье без границ»
22:25 Уроки тафсира (мөфти Камил Сәмигуллин)
22:50 «Учимся совершать намаз» (хатын-кызлар өчен)
23:10 «Готовимся к Рамадану»

# Казан өчен апрель аена намаз вакытлары

| Көн | Көн Исеме | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы/ ифтар | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.04.2021 | Пәнҗ | 02:59 | 3:44 | 5:14 | 12:00 | 16:12 | 18:21 | 20:10 |
| 02.04.2021 | Җом | 02:56 | 3:41 | 5:11 | 12:00 | 16:13 | 18:23 | 20:13 |
| 03.04.2021 | Шим | 02:52 | 3:39 | 5:09 | 12:00 | 16:15 | 18:25 | 20:15 |
| 04.04.2021 | Якш | 02:49 | 3:36 | 5:06 | 12:00 | 16:16 | 18:27 | 20:18 |
| 05.04.2021 | Дүш | 02:45 | 3:33 | 5:03 | 12:00 | 16:18 | 18:29 | 20:21 |
| 06.04.2021 | Сиш | 02:42 | 3:31 | 5:01 | 12:00 | 16:19 | 18:31 | 20:23 |
| 07.04.2021 | Чәрш | 02:38 | 3:28 | 4:58 | 12:00 | 16:21 | 18:33 | 20:26 |
| 08.04.2021 | Пәнҗ | 02:34 | 3:26 | 4:56 | 12:00 | 16:22 | 18:35 | 20:29 |
| 09.04.2021 | Җом | 02:30 | 3:23 | 4:53 | 12:00 | 16:23 | 18:37 | 20:32 |
| 10.04.2021 | Шим | 02:27 | 3:21 | 4:51 | 12:00 | 16:25 | 18:39 | 20:35 |
| 11.04.2021 | Якш | 02:23 | 3:18 | 4:48 | 12:00 | 16:26 | 18:41 | 20:38 |
| 12.04.2021 | Дүш | 02:19 | 3:15 | 4:45 | 12:00 | 16:28 | 18:43 | 20:41 |
| 13.04.2021 | Сиш | 02:15 | 3:13 | 4:43 | 12:00 | 16:29 | 18:45 | 20:44 |
| 14.04.2021 | Чәрш | 02:11 | 3:10 | 4:40 | 12:00 | 16:30 | 18:47 | 20:47 |
| 15.04.2021 | Пәнҗ | 02:07 | 3:08 | 4:38 | 12:00 | 16:32 | 18:49 | 20:50 |
| 16.04.2021 | Җом | 02:02 | 3:05 | 4:35 | 12:00 | 16:33 | 18:52 | 20:53 |
| 17.04.2021 | Шим | 01:58 | 3:03 | 4:33 | 12:00 | 16:34 | 18:54 | 20:56 |
| 18.04.2021 | Якш | 01:54 | 3:00 | 4:30 | 12:00 | 16:36 | 18:56 | 20:59 |
| 19.04.2021 | Дүш | 01:49 | 2:58 | 4:28 | 12:00 | 16:37 | 18:58 | 21:02 |
| 20.04.2021 | Сиш | 01:45 | 2:56 | 4:26 | 12:00 | 16:38 | 19:00 | 21:06 |
| 21.04.2021 | Чәрш | 01:40 | 2:53 | 4:23 | 12:00 | 16:40 | 19:02 | 21:09 |
| 22.04.2021 | Пәнҗ | 01:35 | 2:51 | 4:21 | 12:00 | 16:41 | 19:04 | 21:12 |
| 23.04.2021 | Җом | 01:30 | 2:48 | 4:18 | 12:00 | 16:42 | 19:06 | 21:16 |
| 24.04.2021 | Шим | 01:25 | 2:46 | 4:16 | 12:00 | 16:44 | 19:08 | 21:19 |
| 25.04.2021 | Якш | 01:20 | 2:44 | 4:14 | 12:00 | 16:45 | 19:10 | 21:23 |
| 26.04.2021 | Дүш | 01:14 | 2:41 | 4:11 | 12:00 | 16:46 | 19:12 | 21:27 |
| 27.04.2021 | Сиш | 01:09 | 2:39 | 4:09 | 12:00 | 16:47 | 19:14 | 21:31 |
| 28.04.2021 | Чәрш | 01:03 | 2:37 | 4:07 | 12:00 | 16:49 | 19:16 | 21:34 |
| 29.04.2021 | Пәнҗ | 00:56 | 2:34 | 4:04 | 12:00 | 16:50 | 19:18 | 21:38 |
| 30.04.2021 | Җом | 00:49 | 2:32 | 4:02 | 12:00 | 16:51 | 19:20 | 21:42 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Март саны, №3 (308)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сабирова Ф.И.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБАРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең дана Заказ №2533
Газетага ярты елга язылу бәясе – 170, 04 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 30 нчы мартта таратыла.
График буенча бу санга 29 нчы март көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.